ПИОНЕР КАЛӘМЕ

ФЕВРАЛЬ 1940 № 2

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!
ЛЕНИН—СТАЛИН ЭШЕ ӨЧЕН КӨРӘШКӘ ХӘЗЕР БУЛ!

ПИОНЕР КАЛӘМЕ

БАЛАЛАР ӨЧЕН ЧЫГАРЫЛА ТОРГАН АЙЛЫК ӘДӘБИ ЖУРНАЛ. ВЛКСМ НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ҺӘМ МӘГАРИФ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ ОРГАНЫ.

БУ НОМЕРДА:

Без Сталин армиясе—М. Хөсәенев шигыре 2
Безнең маяк—Ә. Миргазиев шигыре 2
Җиңелмәс армия—мәкалә 3
Хәрби ант 4
Наводчик Лаптев 6
Кызыл армеец Иван Ульянов 7
Кавалерист җыры—Ф. Сиражиев шигыре 8
Пролетар полководец—мәкалә 9
Сиваш буенда 10
Кызыл Армия—Б. Житков әсәреннән өзек. А. Алиш тәрҗемәсе . 12
Серго—А. Марьямов мәкаләсе 16
Ант турында җыр—Лебедев-Кумач шигыре, Х. Туфан тәрҗемәсе . 17
Җәмагат эшләрендә катнашучылар булыгыз—Н. Крупская хаты . 18
Хикәянең дүрт соңы—С. Маршак шигыре, Нур Гайсин тәрҗемәсе . 20
Отличнога уку, дисциплиналы булу—совет укучысының төп бурычы—Г. Шәмсиева мәкаләсе 22
Татар әдәбиятының классигы Шәриф Камал—А. Әхмәт мәкаләсе 24
Авыл мөгаллиме—Ш. Камал хикәясе 25
Сөекле ата—Фаик Камал хикәясе 28
Джордано Бруно—Хәмит Кави мәкаләсе 32
Географик кроссворд . . . .

Редакциянең адресы: Казан шәһәре, Бауман урамы, 19. Матбугат йорты (2 нче кат, 5 нче бүлмә). Телефон № 18—78.

ФЕВРАЛЬ 1940 № 2

Без Сталин армиясе

(Жыр)

1.

Утлы көрәш давылында
Без җиңеп чыктык,
Канлы сугышлар кырында
Туып, чыныктык.

Припев: Без, Кызыл Гаскәр,

Сугышчан яшләр,
Постта нык, уяу
Торыйк, иптәшләр!

Яшлегебез—гөл, нур,
Көннәребез матур,
Иөрәгебез батыр,
Теләгебез зур;
Тормышыбыз рәхәт,
Кызыл маршал, рәхмәт!
Иөрәкләрдә көчле
Сиңа мәхәббәт.

2.

Җимерелмәслек корыч кыя
Илебез һәр чак;
Сталин исме йөрәктә,
Бу исем—байрак!
Припев.

3.

Без—Сталин армиясе,
Шуңа көчле без,
Нинди генә дошманны да
Җиңәр көчебез!
Припев.

Мәхмүт Хөсәенев.

Петропавловск шәһәре.

Безнең маяк

Зур диңгездә бер маяк
Тора юлны күрсәтеп.
Шул маяктай, юлбашчыбыз
Безгә нурларын чәчеп,
Алып бара илебезне
Шат көннәрнең таңына
Һәм менгезә халкыбызны
Бәхет, шатлык тавына!

Әхмәт Миргазиев.

Казан, худ. училищесе.

ҖИҢЕЛМӘС АРМИЯ

Халыкларны ирекле һәм бәхетле итү өчен булган канлы көрәштә безнең данлыклы армиябез туды. Ул—большевиклар партиясенең, бөек юлбашчыларыбыз Ленин һәм Сталин җитәкчелеге астында чынлыкта һәм үсте.

Безнең җиңелмәс Кызыл Армиябез эчке һәм тышкы контрреволюциянең күп көчләрен тар-мар итте, аларны себереп түкте.

Лениннең күрсәтүләре буенча иптәш Сталин иң җаваплы фронтлар белән турыдан-туры үзе җитәкчелек итте һәм Кызыл Армияне яңа җиңүләргә рухландырды.

Гражданнар сугышының түп гөрселдәүләре басылгач, Кызыл Армия халык хуҗалыгын торгызуда җиң сызганып, тырышып эшләде.

Кызыл Армия хәзерге көндә техниканың иң соңгы казанышлары буенча коралланган. Илебезгә һөҗүм итәргә маташучы дошманнарга каршы ул хәзер гражданнар сугышы елларындагы кебек кенә түгел, ә бик күп мәртәбә көчлерәк удар ясаячак.

Безнең армиябез Совет ватанын саклау белән бергә, капитализм тырнагы астында изелүче үзенең туганнарына да ярдәм кулын суза. Ул Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыкларын поляк паннарының изүеннән мәңгегә азат итте.

Хәзер ул үзара ярдәмләшү договоры нигезендә Финляндиянең Демократик Халык Республикасы хөкүмәтенә ярдәмгә килде. Кызыл Армия хезмәт сөючән фин халкын ерткыч Маннергейм-Таннерлар изүеннән коткарачак. Кызыл Армия үз өстенә йөкләнгән бу изге бурычны да зур батырлык белән үтәр.

Әйе, ирекле совет халкының сакланырга тиешле бәхетле тормышы, сакланырлык көче һәм саклаучы батыр уллары бар. Совет халкы иҗад эшенә күмелгән, бөек коммунизмга ул батырларча бара. Данлы Кызыл Армия илебезнең чикләрендә һичбер дошман үтә алмаслык корыч стена булып тора.

Яшәсен безнең җиңелмәс армиябез!

ХӘРБИ АНТ

Мин, Совет Социалистик Республикалар Союзы гражданины, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе сафларына кергәндә, намуслы, батыр, дисциплиналы, сизгер сугышчы булырга, хәрби һәм дәүләт серен нык сакларга, барлык хәрби уставларны һәм командирларның, комиссарларның һәм начальникларның приказларын бер сүзсез үтәргә ант итәм һәм тантаналы вагдә бирәм.

Мин хәрби эшне чын күңелдән өйрәнергә, хәрби милекне һәм халык милкен барлык чаралар белән сакларга һәм иң соңгы сулышыма кадәр үз Халкыма, үземнең Совет Ватаныма һәм Эшче-Крестьян хөкүмәтенә чын күңелдән бирелгән булырга ант итәм.

Мин Эшче-Крестьян хөкүмәтенең приказы буенча үз Ватанымны—Совет Социалистик Республикалар Союзын саклауга барырга һәр вакыт хәзер һәм, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе сугышчысы булуым сыйфатында, мин дошманнар өстеннән тәмам җиңүгә ирешү өчен үземнең канымны һәм тормышымны кызганмыйча Ватанымны батырларча, оста, лаеклы һәм намуслы рәвештә сакларга вагдә бирәм.

Әгәр дә мин үземнең шушы тантаналы антымны усал ният белән бозсам, Совет законы, хезмәт ияләренең гомуми нәфрәте һәм ачуы мине каты җәзаласын.

ВОЕННАЯ ПРИСЯГА

Я, гражданин Союза Советских Социалистических Республик, вступая в ряды Рабоче-Крестьянской Красной Армии, принимаю присягу и торжественно клянусь быть честным, храбрым, дисциплинированным, бдительным бойцом, строго хранить военную и государственную тайну, беспрекословно выполнять все воинские уставы и приказы командиров, комиссаров и начальников.

Я клянусь добросовестно изучать военное дело, всемерно беречь военное и народное имущество и до последнего дыхания быть преданным своему Народу, своей Советской Родине и Рабоче-Крестьянскому Правительству.

Я всегда готов по приказу Рабоче-Крестьянского Правительства выступить на защиту моей Родины — Союза Советских Социалистических Республик и, как воин Рабоче-Крестьянской Красной Армии, я клянусь защищать ее мужественно, умело, с достоинством и честью, не щадя своей крови и самой жизни для достижения полной победы над врагами.

Если же по злому умыслу я нарушу эту мою торжественную присягу, то пусть меня постигнет суровая кара советского закона, всеобщая ненависть и презрение трудящихся.

Подпись И. Сталин

Звание Член Главного Военного Совета РККА

Имя, отчество и фамилия Иосиф Виссарионович

СТАЛИН

Наименование части, управления, учреждения ....

„23“ февраля 1939 г.

НАВОДЧИК ЛАПТЕВ

Киң битле, таза, нык гәүдәле сугышчы янына өлкән лейтенант Маргулис килде:

— Я, иптәш Лаптев, ни хәл? Механизмнар ничек?—дип сорады ул.

— Иптәш өлкән лейтенант, барсы да тәртиптә.

Командир орудиене тагын бер тапкыр карады да үз юлына китте.



Лаптев үзенең эшен бетергәч, җылынырга дип землянкага китәргә җыенганда гына—барлык сугышчыларга да орудиеләр янында булырга, сак торырга!—дигән приказ алынды. Батарея урнашкан районга ак финнәрнең зур бандасы килеп чыккан иде.

Тиздән уң флангдан ак халатлы кешеләр күренде. Алар часовойларның сорауларына каршы ут ачтылар.

Батарея өстенә дошманның пуляләр яңгыры ява башлады. Сугышчылар каушамадылар, дошманга каршы ут ачтылар. Ләкин ак финнәр шундый күп, бер караганда батарея аңа каршы тора алмаслык булып күренә иде.

Бик күп километрлардан ерак цельләргә ата торган, зур-зур ныгытмаларны җимерә ала торган, бөтен бер составларны, дары базларын һавага очыра ала торган бу зур орудиеләр хәзер, дошман янда гына булганда, бөтенләй көчсез булып күренәләр иде.

Орудиеләр янына килеп чыккан өлкән лейтенант Маргулис бер дә аптырамады:

— Ак финнәргә туры наводка белән!—дип команда бирде.

Һәм һич көтелмәгән нәрсә эшләнде: авыр орудиеләр бары 100 метрларда гына торган дошман группаларына төбәлделәр.

— Огонь!—командасы яңгырады.

Орудиедән снаряд атылып чыкты һәм дошман группасының нак уртасына төшеп, каты шартлап ярылды. Аннан икенчесе, өченчесе...

Лаптевның орудиесен дошман үзенең пулемет уты астына алды. Сугышчылар бер-бер артлы егыла башладылар. Яралылар шуышып читкә китәләр иде.

Бераздан Лаптев бер ялгызы калды. Ул, ярдәм көткәндәй, як-ягына карады. Ләкин барлык кеше дә үз эше белән шөгыльләнә, атышу көчәйгәннән көчәя бара. Дошман батареяне ике яктан чолгап алырга маташа иде.

Кызыл Армиягә үзенең ватанын саклар өчен килгән эшче—бурильщик Григорий Лаптев соңгы көченә, үлгәнчегә кадәр, дошманга каршы көрәшергә карар бирде.

Лаптев орудиене төзи, затворны ача, авыр снарядны куя һәм патрон сала һәм... бер ялгызы ата иде.

Аның янына аягы яраланган кече лейтенант Гусев килеп чыкты. Ул уң флангка булышырга кирәклеген әйтте һәм пулемет сорады.

Лаптев тиз генә пулемет алып килде. Гусев пулеметтан атарга керешге. Ат абзары янында ак халатлы бер кеше күренде. Лаптевның соравына ул „үзебезнеке“ дип җавап бирде, Лаптев орудие янына борылгач та, ул аңар атты. Пуля атның ирненә тиде. Лаптев бу дошманның да эшен бетерде.

Совет ватанының турылыклы улы, батыр сугышчысы Григорий Лаптевның бу каһарманлыгы Дан китабына язылды, аңа Советлар Союзы Герое исме бирелде.

КЫЗЫЛ АРМЕЕЦ ИВАН УЛЬЯНОВ

Ленинградта, опера һәм балет театрыннан ерак түгел мәйданда, бер парикмахерская бар. Сез шул парикмахерскаяга керегез дә андагы иптәшләрдән:

— Иван Ульяновны беләсезме? —дип сорагыз. Иван Ульянов биредә 1932 нче елдан 1934 нче елга кадәр эшләде.

Иван Ульянов яхшы парикмахер булса да, призыв җитеп, Кызыл Армия сафларына аны рота парикмахеры итеп алгач, аның бераз хәтре кала.

Ни эшлисең, дисциплинага буйсынырга туры килә. Ульянов бритваларын кайрап эшкә керешә. Аның гүзәл мастерлыгы турындагы дан бик тиз таралып та өлгерә: бер дә кисми, бик шәп кыра, аның бритвасы бер дә борчымый, теләсә нинди прическаны соңгы фасон буенча эшли дә куя. Бер сүз белән әйткәндә, парикмахер түгел, ә художник...

Фин ак гвардеецләренә каршы сугыш башлангач, Ульянов дошманнарны кырырга да вакыт җитте инде дип уйлый.

Көндезен Ульянов армый-талмый бритвасы белән эшли, ә төнлә ул разведкага бара. Разведкага барганда да ул, гадәте буенча, бритва һәм приборларын калдырмый.

Иптәшләре кайчак:

— Әллә юкса генерал сакалын кырырга җыенасыңмы?—дип көлешәләр.

Ульянов:

— Кирәк булса генералны да кырырга була,—ди.

Бер вакыт Иван Ульяновка „А“ авылы тирәсенә барып, разведка ясап кайту эше тапшырыла. Ул үзенең иптәше белән бу җаваплы бурычны үтәргә керешә.

Яктыра башлый.

Разведчиклар таш артына поскан килеш, тирә - якны күзәтеп яталар. Кинәт алда таныш түгел телдә сөйләшкән тавыш иштелә.

Ульянов пышылдап кына:

— Винтовкаңны әзерлә!—дигән команда бирә.

Караңгылык эченнән дошманның шактый зур группасы килеп чыга. Ульянов граната белән аларны тар-мар итә. Ул арада дошман пулеметы тыкылдый башлый. Ульянов бер кулына мылтык, икенче кулына граната тоткан килеш, шуышып барып, дошман пулеметын юкка чыгара.

Кинәт ул ниндидер тавыш ишетә:

— Сез командирмы, сугышчымы?

— Сугышчы, ә нигә?—ди Ульянов.

— Юк, сез гади сугышчы гына түгел. Сез бөркет!

Комбриг, хәзер Советлар Союзы Герое иптәш Вещев, якыннан гына, Ульяновның хәрәкәтләрен күзәтеп торган икән.

Берничә сәгаттән соң безнең частьләребез „А“ авылын алалар. Үлгән ак финнәрнең гәүдәләре юлда аунап ята. Бераз читтәрәк ватык пулемет тора.

Комиссар:

— Молодец!—дип Ульяновның кулын кыса.

Шул көнне Ульянов үзенең куен дәфтәренә:

„Разведкада катнаштым, сугышта булдым. Ак финнәрне граната белән кырдым. Эшне пөхтә башкардык“,—дип язып куя.

Ак финнәргә каршы көрәштә батырлык һәм кыюлык үрнәкләре күрсәткән өчен СССР Верховный Советы Президиумы кызыл армеец Иван Михайлович Ульяновка Советлар Союзы Герое дигән бөек исемне бирде.

Кавалерист җыры

Сынмас кылыч ялтырасын
Кулда яктырак.
Дошман күреп калтырансын
Тагын катырак.

Киттек, атым, еракларга,
Илне сакларга,
Юлбашчыга биргән антны
Эштә акларга.

Чапкан чакта киң илемнең
Далаларыннан,
Утлар чыксын, атым, синең
Дагаларыңнан.

Күтәрелсен тузан күккә,
Тау калсын иңеп.
Без китмибез, атым, күпкә,
Кайтырбыз җиңеп.

Бер чакта да илебезгә
Булмас куркыныч.
Әгәр дошман явы килсә—
Кулларда кылыч.

Яшен яшнәр, күк күкерәр,
Вулкан атылыр,
Безнең көчтән җир тетрәр,
Таулар ватылыр.

Сүнмәс ирек нурын чәчә
Билләрдә кылыч,
Чәчәк атып мәңге яшәр
Киң Ватан тыныч!

Фалих Сираҗиев.
Минзәлә шәһәре.

Пролетар полководец

(М. В. Фрунзенең туууына 55 ел)

1.

1907 нче елның мартында, кулга алынган революционерны Шуй шәһәренең исправнигы Лавров әфәнденең кабинетына керттеләр.

Исправник кергән кешегә карады: аның йөзе яш, күзләре зәңгәр, карашы ачык һәм тыныч иде.

Исправник каләмен карага манып алды да, допрос башларга хәзерләнде.

Кулга алынган кеше: „Ашыгасызмы, әфәнде? юкка ашыгасыз...“— дигәндәй көлде.

Ул бер генә сорауга да җавап бирмәде, елмаеп утыруын дәвам итте һәм сирәк-сирәк кенә сәгаткә карап алды. Сәгат стрелкасы унга җиткәч, кулга алынган кешенең йөзе, бөтен допрос вактында беренче тапкыр, сүрәнләнде һәм күзләре бер урынга төбәлде.



Менә тагын 2 минут үтте—һәм фабрика гудоклары бер юлы улап җибәрделәр.

Забастовка башланды.

Забастовканың башлану вакты исправник кабинетында утыручы яш егет иректә чакта ук билгеләнгән иде. Димәк, бер нәрсә дә комачауламады. Бик яхшы!

Урамнан акрын гына „Варшавянка“ җырлаган тавыш ишетелде. Кулга алынган кеше урыннан сикереп торды да, тәрәзә янына барды һәм җырга кушылды. Исправник стражникны чакыру өчен шашынып звонок шалтыратты, хәтта кулга алынган кешене алып чыккач та, әле ул аңына килә алмый торды.

Икенче көнне үк исправник губернаторга болай дип телеграмма җибәрде:

„Шуйда агитатор Арсений кулга алынды. Бөтен фабрикалар күтәрелделәр. Аны азат итүне сорыйлар. Бәрелешләр булуын көтәм. Полиция идарәсен чолгап алалар. Бик тиз ярдәм кирәк...“

Әйе, агитатор Арсений Шуй шәһәре өчен генә билгеле кеше түгел иде. Бу яш кешене Иваново, Тейков эшчеләре, Кохма, Родников, Панфиловка крестьяннәре дә яхшы беләләр иде. Кайберәүләр аны „Трифоныч“ дип, кайсылары „студентик“ дип атадылар, ә күпчелек аны „иптәш Арсений“ дип йөртте. Болар барсы да партия кушаматлары иде. Петербург политехникумы студенты, большевик Михаил Васильевич Фрунзе әнә шул исемнәр астында яшренеп йөрде.

Жандармнар бу кешедә үзләренең куркынычлы дошманнарын күрделәр. Алар аны ике ел төрмәдә тоттылар.

Алар егерме ике яшлек студентны үлем җәзасына хөкем итәргә мөмкин булсын өчен, аңа каршы иң куркынычлы гаепләүләр эзләделәр.

Һәм аны асарга хөкем иттеләр.

Фрунзе үлем җәзасына хөкем ителгәннәр камерасында бер ай буе утырды. Ул бер генә минутка да тынычлыгын югалтмады. Фрунзе үлем җәзасын көткән вакытта инглиз телен өйрәнде, күпне күргән төрмә хезмәткәрләре дә моңа гаҗәпләнделәр.

Фрунзене аса алмадылар. Хөкем карарына җавап итеп, көчле протестлар күтәрелде, патша хөкүмәте үз фикереннән чигенергә һәм үлем җәзасын гомерлек каторга белән алмаштырырга мәҗбүр булды.

Фрунзе каторгадан качты.

2.

1920 нче елның октябрь ахырлары иде. Кыйналып бетмәгән дошман—барон Врангельнең гаскәре интервентлар тарафыннан ярдәм алып, Кырымга урнашты һәм шуннан торып Украинага янады. Кызыл Армиянең хәл иткеч удары кирәк иде. Өч елга сузылган гражданнар сугышыннан соң килгән менә бу кышны тыныч уздыру өчен, кискен омтылыш ясап, дошманны диңгезгә ташларга, Кырымны алырга кирәк иде. Бу ударны ясауны партия М. В. Фрунзегә тапшырды.

М. В. Фрунзе партиянең бу заданиесен үтәү өчен үз-үзен аямыйча көрәште һәм дошман тар-мар ителде.

Кырымга керү юлы аклардан чистартылгач, Фрунзе Ленингә болай дип телеграмма җибәрде:

„Фронт армияләре республика алдындагы үзләренең бурычларын үтәделәр. Россия контрреволюциясенең соңгы оясы туздырылды“.

3.

1924 нче елда М. В. Фрунзе СССР ның хәрби һәм диңгез эшләре халык комиссарының урынбасары, ә бер елдан соң халык комиссары булды.

Бу елларда Фрунзе безнең данлыклы Кызыл Армиябезне ныгыту өстендә бик күп эшләде. Бу эшне ул иптәш Сталин җитәкчелегендә, иптәш Ворошилов белән берлектә алып барды.

Хәтта каты авыру көннәрендә дә, больницада да, үлем алдында торганда да, армияне ныгыту проектлары өстендә эшләвен ул дәвам иттерде. Ул безнең Кызыл Армиябезне республиканың ышанычлы сакчысы итү турында гына түгел, ә бәлки Советлар иле гражданнарын тәрбияләүче мәктәп итү турында да уйлады.

Сиваш буенда

Караңгы, юеш төн килде. Көнчыгыштан суык, зәһәр җил исте. Кызыл армеецләр, туңган кулларын җылыта-җылыта, костер янына тупландылар. Алда, төн караңгылыгында зур Турецкий вал күренә. Чәнечкеле чыбыклар белән чолгап алынган, төрле ягына пулеметлар һәм орудиеләр урнаштырылган бу вал, Кырым юлында үтә алмаслык киртә булып ята. Аның ныгытмалары артында, Перекоп бугазының теге ягында, соңгы ак генералның—барон Врангельнең гаскәрләре торалар.

53 нче полк штурмга хәзерләнә. Сугышчылар винтовкаларын тотып, дәшмитынмый гына соңгы приказны көтеп торалар. Менә полкка атка атланган берничә кеше килде. Аларның берсе, кыска шинель кигәне, ат өстеннән төште дә батальон командирына таба китте.

— Командующий, иптәш Фрунзе...— дип пышылдаштылар сугышчылар.

Батальон командиры атына менеп атланды да, кулын фуражка янына китерде.

— Отставить,—дип акырын гына команда бирде Фрунзе.—Обстановка миңа билгеле. Берничә минуттан соң атакага барабыз...

Фрунзе кесәсеннән сәгатен чыгарды. Кинәт безнең артиллерия залп белән ата башлады. Сиваш өстеннән авыр снарядлар очтылар.

Артиллерия залпыннан соң булган тынлыкны командующийнең көчле тавышы ярып үтте:

— Кызыл сугышчы иптәшләр! Барлык изелгәннәрнең бөек бәйрәме—Октябрьнең 3 нче еллыгы белән котлыйм.

Бу—1920 нче елда, 7 нче ноябрьдән 8 нче ноябрьгә каршы төндә булды.

Кызыл армеецләрнең куәтле „ура!“ авазы командующийнең тавышын күмде. Ул, шинель итәкләрен ременьгә кыстырган килеш, полк алдында басып тора иде. Аннан соң ул якында гына торган бер кызыл армеецнең кулыннан винтовкасын алып һәм кулын изәп, алга, Сивашка, дошман окопларына таба китте. Сугышчылар үзләренең командующийләре артыннан ташландылар. Һавада көчле „ура!“ тавышы яңгырады. Аклар котырынып пулемет уты ачтылар. Фронт командующие, большевик Фрунзе винтовкасын югары күтәреп, су җырып алга бара иде. Аның янында, әле сул якта, әле уң якта снарядлар ярылалар, һәм аларның утлары аның фигурасын яктырталар. Берничә мең сугышчылар Сивашның салкын суы эченнән, куркусыз рәвештә, аның артыннан бардылар. Кайдадыр җыр яңгырады. Яш тавыш:

„Кузгал ләгнәтләнгән коллар һәм...“,—дип җыр башлады.

Башкалар да:

„Ачлар дөньясы берләшеп“,—дип җырга кушылдылар. Һәм менә пулемет уты астында, билдән су җырып, Турецкий валны штурмларга барганда бу көчле җырга бөтен полк кушылды:

„Бу безнең иң соңгы һәм
Иң кискен зур көрәш,
Интернационалга
Бөтен илләр берләш!“

Турецкий вал ягыннан артиллериядән ата башладылар. Җир тетрәп китте, ләкин сугышчылар туктаусыз алга бардылар. Менә чәнечкеле чыбыкның өч рәтен өзделәр дә инде. Фрунзе алдынгы цепьтә. Владимир Ильич Ленин язган сүзләрне ул исендә тота: „Ничек кенә булса да, дошманның җилкәсенә басып, Кырымга керергә кирәк!“

Ленин сүзләре, партия сүзләре аның өчен закон. Ул үзе шулай тәрбияләнгән иде, пролетар полководец үзенең сугышчыларын да шулай ук тәрбияләде. Пулемет яңгыры астында, снаряд шартлаулары астында сугышчылар соңгы ударга хәзерләнеп, Турецкий вал янында ук җиргә яттылар...

Ике елдан соң, онтылмаслык бу төнне искә алып, Михаил Васильевич болай дип язды:

„Бөтен линиядә дә җиңүгә, гүзәл җиңүгә ирешелде. Ләкин ул безгә бик кыйммәткә төште. Эшчеләр сыйнфы һәм крестьяннәр үзләренең 10 меңнәрчә иң яхшы улларының каны белән, контрреволюциягә каршы соңгы, үлем удары ясадылар. Табигатнең берләшкән көчләренә, техникага һәм үлем утына карыганда революцион омтылыш көчлерәк булды.

Эшчеләр һәм крестьяннәр эше өчен Кырымга керү юлында һәлак булган бу 10 мең герой турындагы истәлек барлык хезмәт ияләренең аңында мәңгегә якты һәм онтылмаслык булырга тиеш“.

Югарыда: Васильеводагы урманчылык комбинаты клубы каршындагы авиамодель түгәрәгендә занятие вакты. Михайлов фотосы. (ТатТАСС фотохроникасы).

Түбәндә: Иваново шәһәрендәге пионерлар Дворецының хәрби кабинетында тактик занятие вакты. Шаровский фотосы. (ТАСС фотоклишесе).

Һәрбер сүзгә каршы: „Ни өчен?“—дип сорау бирә торган Алеша исемле малайны күпләр „Почемучка“ (Почему дигән сүздән алынган) дип йөртәләр. Менә шул малай әбисенә дачага кунакка барырга юлга чыга һәм маневрга баручы Кызыл Армия частьләренә очрый.

Алеша бик күп кызыклы нәрсәләр күрә. Аның күргәннәре белән танышырга теләгән укучы Б. Житковның „Мин нәрсәләр күрдем“ исемле әсәрен укырга тиеш. Бу китап татарчага да тәрҗемә ителә.

Мәктәпкәчә яштәге балалар һәм кече яштәге укучылар өчен язылган бу әсәрнең без бер өлеше белән укучыларыбызны таныштырабыз.



БЕЗ НИЧЕК МОСКВАДАН КИТТЕК

Кулына чемодан тоткан кешенең рәсме төшерелгән кнопканы басарга мин әнидән рөхсәт сорадым.

Әни:

— Я алайса шылтырат, тик бик нык басма,—диде.

Мин шылтыраттым. Һәм бик тиз генә бер абый килеп тә җитте. Ул теге лифт йөртүче абый төсле үк. Ул да баштан аяк коречневыйдан киенгән, төймәләре дә алтыннан. Керде дә:

— Сезнең әйберләрегезне алып чыгаргамы?—диде.

Чемоданны эләктереп, күтәреп тә китте, ә без әни белән лифтка утырып, түбәнгә төшеп киттек.

Түбәнгә төшеп җитсәк, теге абый чемодан белән күптән инде түбәндә тора. Мин аңар, без автобуска утырып әбигә барабыз, дидем.

Автобус ул вагон шикелле үк автомобиль. Анда диван кебек йомшак скамьяләр дә, алдарак пияла шкаф шикелле кечкенә бүлмә дә бар. Анда шофер утыра, ул автомобильне йөртә. Без әни белән автобустагы скамьягә утырдык. Карарга җайлы булсын дип, мин тәрәзә буена ук утырдым.

Безнең алдагы урында хәрби кием кигән бер абый утыра иде. Ул үзе буйга бик озын. Шуның аркасында миңа шоферның автомобильне ничек йөртүе бөтенләй күренмәде.

Башта без урам буйлап бардык, мин йортларга карап бардым.



Ә йортларда бик күп магазиннар һәм кинолар бар. Кино булган җирләрдә төрле көлке кешеләрнең рәсемнәрен ясап куйганнар.

Берсенең рәсмен зур итеп, кисеп эшләгәннәр, үзе басып тора. Мин аны тере кешедер дип торам. Аннан без өйләр юк урыннан уза башладык. Як-якларыбызда агачлар да агачлар.

Әни:

— Я, Москва белән саубуллаш. Бу урыннан инде дачалар башланды,—диде.

ХӘРБИ КИЕМЛЕ АБЫЙ

Хәрби киемле абый миңа таба борылды да:

— Тиздән без урманга җитәбез. Чын урман, анда бүреләр дә бар,—диде.

Мин әлек аз гына курыктым, аннан соң абый шаяртадыр дип уйладым.



Мин көлеп җибәрдем һәм әйттем:

— Ха-ха-ха! Без бүреләрне хәйваннар бакчасында күрдек. Алар читлектә утыралар!

Ә теге абый әйтә:

— Ә анда алар читлектә утырмыйлар шул. Урманда алар „һам!“ иттереп тешли дә алалар. Ул чак болай көлмәссең,—ди.

Әни:

— Абыең аучыдыр ахрысы, урманда ул нинди бүреләр барлыгын да бик яхшы белә,—диде.

Ә теге абый:

— Мине бүреләр дә таныйлар. Мин аучы шул,—ди.

Ә мин:

— Ә мылтыгыгыз кая соң?—дим.

Абый кинәт кенә иелде дәниндидер бер озын капчык сөйрәп чыгарды. Йодрыгы белән капчыкка сукты, анда ниндидер каты бер әйбер бар. Һәм:

— Менә ул минем мылтыгым, менә кайда. Өйдә минем ике этем дә бар,—дип әйтте.

Мин аңардан:

— Көдрә йонлылармы?—дип сорадым.

Әни ачуланды һәм:

— Абыеңны йөдәтмә!—диде.

Мин аның капчыктан мылтыгын алып, миңа күрсәтүен көтеп бардым.

Безнең тирә-ягыбызда агачлар үсеп утыралар иде. Һәм мин һаман сорадым:

— Урман шушымы инде, әллә юкмы?

Ә теге абый һаман әйтте:

— Бу нинди урман булсын, болар әле бар да дачалар.

СУГЫШ

Без юл буенча бардык. Автобус тирбәлгәнгә күрә, мин йокыга киткәнмен.



Аннары мин кинәт уянып киттем.

Безнең автобус туктаган һәм тирә-ягыбызда зур-зур агачлар үсеп утыралар.

Мин:

— Ни өчен?—дидем.

Безнең автобустагы барлык кешеләр дә:

— Ни өчен. Ни өчен тукталы?—диештеләр.

Хәрби кием кигән абый утырган урныннан торды да, автобустан чыкты. Аннары тәрәзә янына килеп безгә:

— Кызыл Армия уза!—диде.

Мин кычкырып җибәрдем:

— Сугыш!

Әни:

— Әллә нинди җүләр сүзләр сөйләп утырма әле!—диде.

Хәрби киемле абый:

— Әйе шул, сугыш. Ә чын сугыш түгел, юри-малый гына,—диде.

Әни утырган урыннан сикреп торды да сорады:

— Әллә хәзер атарга да тотыначаклармы?

Һәм колак тишекләренә бармакларын тыкты.

Хәрби киемле абый:

— Яш кешене бирегә китерегез әле!—диде.

Мин тизрәк тәрәзәдән тышка таба сузылдым.

Теге абый мине култык астымнан тотты да тәрәзәдән күтәреп алды, ә әни моны күрми калды.

Әни шундый курыкты, хәтта күзләрен дә йомды. Хәрби киемле абый мине җилкәсенә атландырды, миңа барлык нәрсә дә күренә башлады. Алда анда агачлар юк, ап-ачык кыр һәм анда милиционер түгел, ә кызыл армеец басып тора. Ул кулына флаг тоткан.

Ул без үтеп китмәсен дип кулына шулай флаг күтәргән икән. Бер кем дә йөрмәсен дигән сүз.

Аннан соң кызыл армеецләр уза башладылар, шундый күп, шундый күп, бар да башларына тимер каскалар кигәннәр, җилкәләренә мылтыклар асканнар. Алар җыр башлап җибәрүгә автобустагыларның барсы да сикреп төштеләр һәм аларны карарга керештеләр.

Ә әни:

— Алешка кая, Алешка кая?—дип кычкырына. Үземине күрми. Мин барыннан да биек булып, теге абыйның җилкәсендә утырып торам.

БЕЗНЕҢ ЯНЫБЫЗДАН МЕНӘ НӘРСӘЛӘР УЗДЫ

Аннары, тәгәрмәчле пичләргә җигелгән атлар уздылар. Ул пичнең морҗасы нәзек кенә. Теге хәрби абый әйтә: кухня узып бара, ди. Ул кухнядә төрле-төрле ашлар һәм бутка пешерелә.

Аннары атка атланган кешеләр уздылар.

Барсы да:

— Кавалерия килә,—диештеләр.

Ул кавалерия дигәннәре атка атланган, кылыч һәм мылтык таккан кызыл армеецләр икән. Атлары аларның барсы да җирән, алар да кызыл армеецләр кебек тезелешеп, саф-саф булып баралар. Хәрби киемле абый әйтә, алар өйрәтелгән атлар, чөнки аларны шулай йөрергә өйрәткәннәр, ди.

Аннары, кулларына чәнчи торган сөңгеләр тоткан кызыл армеецләр уздылар. Тик алар сөңгеләренең очлы башларын өскә таба күтәреп тотып бардылар. Чөнки сугыш юк бит әле.



Теге абый миңа:

— Менә болар казаклар,—диде.

Аннары, казаклар артыннан, кыр буйлап нindидер өйчекләр уза башладылар. Үзләре сорылар. Өстә башняләре бар. Башнясеннән мин таяк чыгып тора дип уйладым.

Теге абый көлде дә:

— Ул таяк түгел ич, ә пушка!—диде.

Ә ул өйләр тимердән эшләнгәннәр.

Пушкасыннан атып торып җибәрсә, түзеп кенә тор! Ә ул өй шундый нык, аңар мылтыктан атсаң да бер ни булмый.

Ул—танк. Аның эчендә кешеләр утыралар. Хәрби кешеләр. Алар танклары белән теләсә кемне сытып уза алалар. Дошманнар алардан бер кая да качып котыла алмыйлар. Чөнки танк теләсә кая бара ала. Ул агачка килеп төртелсә, агачны да аудара ала. Туп-туры өй өстенә барып керсә, өйне дә җимереп үтә. Теләсә суга да чума, су астыннан да бара ала.

Ә инде пушкасыннан теләсә кемне атып үтерә ала. Тик бер кем дә атмады. Алар ян-якка таба, кыр өстеннән туп- туры каядыр киттеләр. Алар ничек сугышырга кирәклекне өйрәнәләр.

Аннары бер ни дә узмый башлады.

Барсы да:

— Хәзер китәбез!—диештеләр.

Барсы да автобуска утырыша башладылар. Теге абый да мине җиргә төшерде.

Әни автобус эченнән:

— Улымны бирегә бирегез, хәзер китәбез,—дип кычкырды.

Кинәт ниндидер бер кызыл армеец килде, җиңенә ак бәйләгән, ул:

— Бер кая да алга үтәргә ярамый, тик артка таба китәргә генә мөмкин,—диде.

Безнең шофер:

— Ә безгә соң бик озак көтәргә туры киләчәкме?— диде.

Кызыл армеец, кичкә кадәр торырсыз ахры, ди. Без бер кая да китмәдек.



ӨСТӘН ТОРЫП НИЧЕК СУГЫШАЛАР

Мин дә күктә кошка ошашлы өч нәрсә очып баруын күрдем. Алар кошлар түгел, ә самолетлар иде. Аннары тагын өч, аннары тагын... Күктә алар бик күп иде. Бая алар үкергәннәр икән.

Мин аларның очуларын һаман-һаман карап тордым. Алардан кинәт ниндидер кечкенә-кечкенә генә гөмбәләр түбәнгә төшә башладылар. Барсыннан да шулай коелдылар һәм сабын куыклары төсле әкрен генә түбән төштеләр.

Мин:

— Ни өчен, ни өчен?—дип кычкырып җибәрдем.

Теге абый әйтә, алар кызыл армеецләр шулай сикерәләр, ди. Һәрбер кызыл армеецнең шундый зонтигы бар. Хәрби кием кигән абый әйтә: ул зонтик—парашют, ди. Ул ачылып китә, шуңа күрә кызыл армеец түбән кинәт төшеп китми, ә әкрен генә төшә. Шуңа күрә, җиргә килеп бәрелсә дә, бер җирен дә авырттырмый. Аның үзе белән мылтыгы да бар. Ул очып җиргә килеп төшкәч, мылтыгын тотып сугышырга барачак, мылтыгыннан ата да башлаячак.



Самолетлардан кызыл армеецләрне генә төшермиләр, ә бомбалар да төшерә алалар. Бомба җиргә килеп төшә дә, туп аткандагы шикелле, бик каты шартлый.

А. Алиш тәрҗемәсе.

СЕРГО

Григорий Константинович Орджоникидзене Бөек октябрьгә кадәр күп вакыт элек, 1903 нче елда ук, „Серго“ дип атый башладылар. Ул вакытта Григорий Константинович 17 яшлек яш егет иде. Ул шул вакытта ук Закавказье большевиклары оешмасына керде. 19 яшендә вакытта ук Орджоникидзе партиянең Сухум округ комитеты члены иде. Үзенең эзен полициядән югалту өчен, революционерлар бер-берсен чын фамилияләре белән түгел, ә уйлап тапкан фамилияләр, кушаматлар белән атыйлар иде. Шулай ук „Серго“ да—Григорий Константинович Орджоникидзенең партия кушаматы.

Серго 1906 нчы елда, Тифлис большевиклары газетасы редакциясендә беренче тапкыр буларак иптәш Сталин белән очрашты. Шул вакыттан алып, үзенең соңгы көненә кадәр, утыз бер ел буена; большевиклар революциягә хәзерләнгәндә дә һәм алар дөньяда беренче булган социалистик дәүләт төзегәндә дә Серго Орджоникидзе иптәш Сталинның иң якын көрәштәшләреннән берсе булды. Серго 1911 нче елда, Париж янындагы француз авылы Лонжюмода Владимир Ильич Ленин оештырган партия мәктәбендә укыды. Аннан соң Серго Россиягә кайтты һәм илдә партия эше белән җитәкчелек итүче Үзәк Комитет бюросы составына сайланды. Бюро белән Иосиф Виссарионович Сталин җитәкчелек итә иде. Ләкин ул вакытта иптәш Сталин патша жандармнары тарафыннан төньяктагы Вологда шәһәренә сөргенгә җибәрелгән иде. Орджоникидзе яшренеп кенә Вологдага барды һәм алар иптәш Сталин белән берлектә, подпольедәге большевиклар оешмасы эшләргә тиешле эшләрнең планын төзеделәр.

Серго тиздән полиция тарафыннан кулга алынды. Һәм аны Шлиссельбург крепостына өч елга ябып куйдылар, ә аннан соң—1915 нче елда—аны ерак Якутиягә, сөргенгә җибәрделәр.

Россиягә, Петроградка, Серго бары тик февраль революциясеннән соң гына, 1917 нче елның җәендә генә кайтты.



Бер вакытны Сталин Григорий Константинович Орджоникидзене партиянең VI нчы съездына хәзерлек турында киңәшергә Ленин янына җибәрде. Серго төнлә белән Сестрорецкий янындагы кечкенә генә станциягә килде. Берәр кеше күзәтмиме икән дип тирәякка каранды да, Ленин яшренеп торган станция эшчесенең йортын эзләргә китте. Бу эшченең ун яшлек улы Сергоны күл янына алып барды, һәм алар көймәгә утырып күлнең икенче ягына чыктылар да, куе куаклыклар арасыннан бардылар. Печән кибәне янына килеп җиттеләр һәм малай шунда кемнеңдер исмен әйтеп, акрын гына эндәште. Аның атасы килде, ә аннан соң, сакал-мыекларын кырган, таныш булмаган бер кеше якынлашты. Бу кеше Сергога карап торды да кинәт көлеп җибәрде һәм аның җилкәсенә кулын куеп:

— Әллә, иптәш Серго, танымыйсыңдамы?—диде.

Бу кеше Ленин иде. Алар кара икмәк белән селедка ашадылар да (ашарга башка

әйберләре юк иде), хуш исле печән кибәненә таба киттеләр. Ленин һәм Серго бередә бик озак сөйләшеп утырдылар. Алар зур җиңүләр турында сөйләштеләр.

Гражданнар сугышы беткән иде инде, ил бөек төзелеш эшенә керешкән иде һәм шул вакытта—1930 нчы елда—Серго Орджоникидзе СССР халык хуҗалыгының Югары Советы председателе булып, ә аннан соң авыр промышленность халык комиссары булып билгеләнде.

Сестрорецкий янында Владимир Ильич Ленин белән, Петербургның тар бүлмәсендә иптәш Сталин белән уйлаган хыялларны хәзер аңа үз куллары белән иҗад итү бурычы тора иде. Ул халык хуҗалыгының бөтен тармакларында булды. Сергоны әле Днепр ярлары буенда, әле Уралда—Березникида, Соликамскийда, Магниткада күрделәр. Серго Сталинградта, Донбасста, Кольский тундырасында, Бакуда, Кузнецкида да еш була иде. Һәм һәр кайда да җитәкчеләр белән, инженерлар белән, гади эшчеләр белән сөйләшә, аларның эшләре белән таныша һәм аларны яңа җиңүләргә рухландыра иде.

1935 нче елның ноябрендә Серго телеграмма биреп, Стахановны Москвага чакыртты.

— Менә нинди икән ул Стаханов,—дип шаяртты ул беренче очрашуда.—Ә мин аны бик көчле кешедер дип уйладым...

Ә аннан соң, утыргач, Серго болай диде:

— Я, сөйләгез, эш ничек булды. Һәм игтибар белән тыңлый башлады.

Серго Орджоникидзе дәүләтнең зур эшлеклесе, Лениннең һәм Сталинның иң яхшы шәкерте, большевиклар партиясенең һәм халыкның сөекле улы иде. Ул үзенең бөтен гомре буена халык дошманнарына каршы көрәште. Соңгы сулышына кадәр ул социализмның бөек эше өчен көрәште һәм аның турындагы якты истәлек безнең йөрәкләрдә саклана.

А. Марьямов.

АНТ ТУРЫНДА ЖЫР

ВАС. ЛЕБЕДЕВ—КУМАЧ

Сакчысы мин данлы ватанымның
Һәм улы мин хезмәт халкымның,
Мин ант итәм: ил сакчысы дигән
Зур исемне аклый алырмын.

Мин ант бирдем бөек ватаныма,
Мин ант бирдем бөтен халкыма,
Бер адым да артка чигенмичә,
Барачакмын дошман каршына.

Мин яш батыр; сугышачакмын мин:
Безнең хаклык—дөреслек өчен,
Кызыл йолдыз, урак-чүкеч өчен,
Җиребез һәм иркебез өчен!

Ант итәм мин илгә һәм халкыма
Мин үтәрмен биргән антымны,
Дошманнарга каршы сугышканда
Кызганмам мин көч һәм канымны.

Саклармын мин совет державасын
Туры, кыю хезмәт итәрмен,
Кызыл Армиянең батыр данын
Какшатырга ирек бирмәмен.

Х. Туфан тәрҗемәсе.

Н. К. КРУПСКАЯ

Моннан бер ел элек, 1939 нчы елның 27 нче феврэлендә, безнең илебезнең турылыклы кызы, бөек Лениннең көрәштәше һәм гомер иптәше, ВКП(б) Үзәк Комитеты члены, СССР Верховный Советы депутаты Надежда Константиновна Крупская үлде.

Надежда Константиновна эшче сыйнфын культуралы итүгә бөтен тормышын багышлады. Эшчеләр өчен ачылган кичке мәктәпләрдә ул халык укытучысы булып эшләде. Хезмәт ияләренең бәхте өчен, революциянең җиңеп чыгуы өчен Владимир Ильич белән бергә, ул кулга кул тотынып көрәште.

Надежда Константиновна совет балаларын бик сөя иде. Ул аларны культуралы, һәр яктан белемле булып үсәргә чакырды. Аның ялкынлы сүзләре безнең йөрәкләргә һәр вакыт килеп җитәләр иде. Аның туры юнәлеш күрсәткән җылы сүзләре безне алдагы, яңа җиңүләргә рухландыра.

Надежда Константиновнаның совет укучыларына карата әйткән сүзләре бүген дә безнең арабызда, аның бөек образы безнең күз алдыбызда яши.

Н. КРУПСКАЯ

Җәмагат эшләрендә катнашучылар булыгыз

Кадерле балалар!

Сез хәзер мәктәптә тәртип булдыру өчен көрәшәсез, уку ударниклары булу өчен тырышасыз. Белем—ул зур көч һәм аның патша вактындагы кебек булырга тиеш түгеллеген дә сез беләсез: ул вакыт белем алпавытлар һәм капиталистлар һәм аларның иярченнәре кулында иде, ә хезмәт ияләрен, эшчеләрне һәм крестьяннәрне караңгылыкта һәм наданлыкта тоттылар. Белем өчен көрәшү—бик зур эш ул.

Сез мәктәптә 5—6 сәгат кенә вакыт үткәрәсез, ә калган вакыт эчендә мәктәптән тыш, тормышның кайнап торган җирендә яшисез. Сез зурлар арасында торасыз, аларның нәрсә турында кайгыртуын беләсез, аларның сөйләшүләрен ишетәсез. Өйдәге, урамдагы, ишек алдындагы сөйләшүләрне ишетәсез, сез тормыш турында уйлыйсыз һәм андагы бик күп нәрсәне әле үзгәртергә кирәклекне күрәсез.

Сезнең күбегез пионерлар. Сезнең вожатыйларыгыз, пионер булу—кызыл галстук йөртү генә түгел ул дип, сезгә бик дөрес сөйлиләр. Пионер булу—әйләнә - тирәдәге тормышны яхшыртуда катнашу, шуны ничек эшләү турында уйлау дигән сүз. Һәм һәрбер пионер мәктәптә генә түгел, ә мәктәптән тыш та бу эштә катнашырга тиеш. Ә кайчак болай да булгалый: мәктәптә „пионер—барлык балаларга да үрнәк“, ә мәктәптән чыккач—нак бәйдән ычкынгандай, үзенең пионер икәнлеген уйларга да оныта, ничек кенә булса да киногә керү яки аз гына хулиганлык эшләү турында гына уйлый. Ә җәмагат эше турында исенә дә кертми, җырларда әйтелгәнчә, большевиклар миннән башка да башкарырлар әле, ди.

Бик күп балалар җәмагат эшенең нәрсә икәнен бик ачык итеп күз алларына китереп бастыра алмыйлар. Җәмагат эше—ул әйләнә-тирәдәге тормышны бергәләп яхшыртуга юнәлдерелгән эш.

Менә, мәсәлән, сез торган йортта балалар бакчасы бар, сез балаларның уенчыклары юклыгын, кечкенәләргә күңелсез икәнлеген күрәсез. Берничә кеше түгәрәккә оешыгыз, кечкенә ба-

лаларга берничә уенчык ясагыз, чиратлашып алар белән уйнарга йөрегез. Яки сез, үзегез тора торган авылда, ниндидер сәбәпләр белән, үз вактында мәктәпкә керә алмый калган, укый-яза белми торган яш үсмерләр булуын күрәсез. Алар укырга телиләр, ә укытучылар җитешми. Алар белән эш оештырыгыз, алар өчен кәгазьләр яки дәфтәрләр, төрле уку китаплары табыгыз һәм үзегез нәрсә укыган булсагыз, аларга да шуны укытыгыз. Бу бик кирәкле эш. Яки сезнең авылда зурлар мәктәбе бардыр. Зурлар мәктәптә география фәнен өйрәнәләр, ә аларның карталары юк. Сез зурлар мәктәбе өчен карта эшләсәгез иде, сезне бу эшкә өйрәтәләр—һәм сезнең күбегез карта сызарга ярата, моны ничек эшләгәндә яхшырак булыр, уйлагыз әле. Зурлар мәктәбе укучылары бу эшегез өчен сезгә рәхмәт әйтерләр.

. . . .

Тирә-юндә пычрак булган урыннарны күрсәгез, уку залларында, ашханәдә, ясляләрдә, балалар бакчаларында чисталык булдыру өчен, поход оештырыгыз.

Мин моны мисаль итеп кенә әйтәм. Тирә-юндә нәрсәнең тиешенчә эшләнмәгәнлеген сез үзегез күрегез, теге яки бу эшне яхшырту өчен нәрсә белән һәм ничек ярдәм итә алуыгыз турында бергәләп тикшерегез.

Җәмагат эшләрендә эшләүче зурларның ярдәмчеләре булыгыз, һәм сез бу эштә Ленин—Сталин эше өчен көрәшә белүче җәмагат эшчеләре булып үсәрсез.

1938 ел.

РӘСЕМДӘ: Колпинск авылы мәктәбенең (Белоруссиянең көнбатыш өлкәсе) укытучысы Е. Н. Львова Советлар Союзы турында, хезмәт ияләренең юлбашчысы иптәш Сталин турында балалар белән беседа үткәрә. Д. Чернов фотосы. (ТАСС фотоклишесе).

Хикәянең дүрт соңы

С. Маршак

Унынчы мәктәпкә
Бара трамвай,
Буферга ябышкан
Блинов Николай.

Трамвай—урам буйлап,
Трамвай—шосседан,
Ә трамвай артына
Блинов аслынган.

Трамвай туктады.
Урам уртасы.
Трамвайга керде
Блинов атасы.

Кешеләр утырган
Вагонга тулып.
Тәрәзәдән карый ул
Урыннан торып.

Рельс буйлап күзен
Йөртә еракка,
Баганалар тезелеп
Чигенә артка.

Як-якта кала
Ком һәм үләннәр.
Кинәт тәрзәдән
Бер баш күрәләр:

Кашын җыерган ул,
Ачкан авызын,
Атасы таныды
Булдыксыз улын.
Төбәлеп ике күз
Атага карый.

Инде—хикәянең
Дүрт соңы. Ярый,
Башлап күңеллесен
Сөйләрбез сезгә:
Блинов һәм атасы
Кайталар өйгә.
Атасы трамвайда
Кайта утырып.
Ә улы буферда,
Артка тотынып.
Атасы түләде
Нак унбиш тиен,
Ә Николай кайтты
Билетсез көе.

Хәзер кызганычын
Сөйлибез сезгә:
Блинов һәм атасы
Кайттылар бергә.

Блинов кайтып җитә
Билетсыз өйгә.
Аның өчен штраф
Атасы бирә.





Куркынычлысын без
Сөйлибез сезгә;
Блинов һәм атасы
Кайталар бергә.
Атасы трамвайда
Кайта утырып.
Ә улы буферда,
Артка тотынып.
Өйләре турында
Тартылды трамвай,
Буфердан егылды
Блинов Николай.
Трамвай юлына
Җыелды халык,
Тиз ярдәм килде дә
Китте аны алып.

Больницада ята
Мескен, селкенми.
Дүрт сестра аның
Янында йөри,
Хәрәкәтсез ята
Ул палатада
Ап-ак халат кигән
Доктор алдында.
Ахырын инде
Син үзең уйла,
Кем тиз таба ала,
Шул егет була.
Ләкин барыгыз да
Тотыгыз истә:
Трамвайга ябышу
Ярамый һич тә.

Нур Гайсин тәржемәсе.



Отличнога уку, дисциплиналы булу— совет укучысының төп бурычы

Г. Шәмсиева

ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре

1939 нчы елның 19—23 нче декабрьләрендә, Москва шәһәрендә, комсомол Үзәк Комитетының X нчы пленумы булып үтте.

Бу пленумда ВЛКСМ Үзәк Комитетының секретаре иптәш Михайлов комсомолның мәктәптәге эше турында зур доклад ясады.

Иптәш Михайлов, докладының керешэлешендә үк, большевиклар партиясенең һәм турыдан-туры иптәш Сталинның мәктәпләр эшенә зур әһәмият бирүләрен һәм өзлексез кайгыртуларын күрсәтеп үтте. Иптәш Михайлов мәктәпләрдә уку сыйфатын күтәрүдә, балалар арасында үрнәк тәртип булдыруда комсомол оешмалары алдында торган бурычларга тукталды. Хәзер комсомол оешмалары бу бурычларны үтәү өчен үз эшләрен үзгәртеп корырга тиешләр.

Комсомол барыннан да элек укытучыга булышлык күрсәтергә тиеш. Комсомол оешмалары бик күп кенә вакытларда укытучының ничек эшләвен, аңар нәрсә белән ярдәм итәргә кирәклеген бөтенләй белмиләр. Укытучы белән киңәш итмиләр, укытучының язмышына салкын карыйлар.

Мәсәлән, комсомолның Казан Шәһәр комитеты һәм Сталин райкомы, 1939 нчы ел эчендә, укытучы эше белән бәйле булган бер генә мәсьәләне дә тикшермәгәннәр.

Комсомол оешмалары һәм пионер отрядлары укытучының көндәлек эшенә чын-чынлап ярдәм итәргә тиешләр.

Укучылар үзләрен тотуда һәр урында да җаваплылар. Өйгә бирелгән заданиеләрне үтәмәүчеләрне, вакытын бушка уздыручыларны, мәктәп җиһазларын җимерүче - бозучыларны яшь буларына карап һич тә акларга ярамый. Мәктәп җиһазларын җимерү, вату, завод, фабрика, колхоз машиналарын бозу кебек үк, җинаят булганлыгын укучылар аңларга тиешләр. Тырышып уку, җәмагат эшләрен төгәл һәм күңел биреп үтәү, мәктәп җиһазларына карата сак булу, дисциплиналы булу, үз-үзеңне пөхтә йөртү—менә болар барсы да совет укучысына хас булган сыйфатлар.

Укучыларның дисциплиналы булулары иң элек аларның өлгерешләренә йогынты ясый. Укучылар үзләрен яхшы тотсалар, аларның уку нәтиҗәләре дә яхшы була. Заданиеләрне үтәмәү, дисциплинасыз булу, фәннәрне өстән-өстән генә өйрәнү—менә болар барсы да укудан өлгермәүгә илтәләр һәм шуның аркасында бер класста ике ел буена утырып калучылар да була.

Мәктәпләрдә уку буенча өлгерешне һәм дисциплинаны күтәрүдә пионер отрядлары бик зур урын тоталар.

Партия һәм комсомол җитәкчелеге астында пионер отрядлары миллионнарча совет укучыларын җәмагат тормышына якын китерәләр. Аларның дөньяга карашларын киңәйтәләр. Балаларда социалистик ватанга булган мәхәббәтне тәрбиялиләр. Безнең илнең балалары пионер оешмаларын яраталар. Пионерлардан үрнәк алалар.

Отрядлар барыннан да элек уку сыйфаты өчен көрәшергә, балаларны пионерлар сафына тарту өчен көрәшергә тиешләр. Пионер отрядларының сборларын, аны балалар көтеп алырлык итеп, алдан хәзерләп, план буенча, кызыклы итеп оештырырга кирәк.

Татарстандагы 200 ләп пионер отрядында әлегә кадәр вожатыйлар юк. Вожатыйлары булган отрядларның да кайберләрендә эш бик начар куелган. Отрядларның, звеноларның начар эшләүләре нәтиҗәсендә кайбер пионерлар уку һәм дисциплина буенча башка балаларга караганда артта баралар.

Балаларны хәрби-физкультура түгәрәкләренә тартырга, илебезнең атаклы кешеләре катнашы белән балалар өчен кичәләр оештырырга, яшь туристлар, техниклар, натуралистлар белән эшләргә кирәк. Һәр мәктәп каршында алма бакчалары, яшелчә бакчалары, чәчәк

утырта торган түтәлләр булдырырга кирәк.

Пионер йортлары, балалар техник станцияләре һәм мәктәптән тыш башка оешмаларның да эшләрен яңа баштан корырга кирәк. Алар безнең укучыларыбызның теләкләрен тулысынча үтәргә тиешләр. Чистай районындагы балалар техник станциясе әле бик начар эшли. Бу станциягә бары 41 бала гына тартылган. Иң кызыклы түгәрәкләрдән саналган авиамодель түгәрәгенә бары тик 7 укучы, яш натуралистлар түгәрәгенә 9 укучы гына йөри. Станция райкомолдан да, шәһәр мәгариф бүлегеннән дә бер төрле ярдәм күрми.

Физик һәм оборона тәрбиясе һәрбер укучы өчен һава кебек кирәк. Безнең укучыларыбыз илебезнең көчле, кыю һәм сугышчан сакчылары булып үсәргә телиләр. Ләкин әле безнең бу өлкәдәге эшләребез һич тә җитәрлек түгел.

Комсомол Үзәк Комитетының X нчы пленумы укучыларның Бөтенсоюз яш физкультура җәмгыятен төзәргә карар бирде. Билгеле, мондый җәмгыят яш физкультурниклар армиясен оештырыр, физкультура тәрбиясен җәеп җибәрүдә комсомолга зур ярдәм итәр. Хәзер үк барлык мәктәпләрдә, ишек алларында, мөмкин булган барлык урыннарда спорт мәйданнары төзергә кирәк.

Комсомол Үзәк Комитетының X нчы пленумы балаларның художество үзешчәнлеге турында аерым доклад тыңлады. Һәм пленум балалар арасындагы талантларны тагын да үстерү өчен балаларның Бөтенсоюз художество үзешчәнлеге олимпиадасы уздырырга карар чыгарды.

Пленум шулай ук балалар әдәбиятының торышы һәм бурычлары турында аерым доклад тыңлады. Совет балаларына идея ягыннан тотнаклы, югары художестволы әсәрләр бирү өчен махсус чаралар күрелде.

Татарстанның XX еллыгы якынлаша. 1940 нчы елның 25 нче июнендә Татарстан хезмәт ияләре бу данлыклы юбилейне билгеләп үтәчәкләр. Бу көн безнең барыбыз өчен дә шатлыклы бәйрәм көне булачак. Татарстан юбилейен отлично билгеләре белән һәм үрнәк дисциплиналы булу белән каршылау—һәрбер комсомолецның, пионерның, совет укучысының иң мөһим бурычы. Социалистик ярышны киң җәелдерү белән без бу бурычны тулысынча үтәргә тиешбез. Балаларны политик яктан чыныктыру һәм культуралы итеп тәрбияләү, совет мәктәбен ныгыту һәм үстерү өлкәсендә Татарстан комсомолының казанышлары Татарстанның XX еллыгы уңышлары рапортында күренекле урынны алырга тиеш. Безнең Татарстан балалары республикабызның гүзәл юбилеенә ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумының карарларын уңышлы утәрләр, фәннәрдән өлгерештә һәм үз-үзләрен тотуда гүзәл уңышларга ирешерләр.



РӘСЕМДӘ: Борислав шәһәрендәге нефть промыслолары.
Н. Цидилковский фотосы (ТАСС фотоклишесе).

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ КЛАССИГЫ ШӘРИФ КАМАЛ

Шәриф ага Камал Бөек Социалистик Октябрь революциясенә кадәр үк танылган язучы. Ул элекке патша Россиясенең иң авыр, реакциянең иң көчле елларында яза башлый. Аның иң беренче хикәясе 1909 нчы елда, Оренбургта (хәзер Чкалов шәһәре) чыга торган „Шура" журналында басыла.

Шәриф ага өч дистә еллар буе, кулыннан каләмен төшермичә, татар әдәбиятын баету юлында армый-талмый хезмәт итеп килә. Ул утыз еллык әдәби хезмәтенең егерме елын азатлыкка чыккан хезмәт халкының героик көрәшен һәм тормышын яктыртуга багышлады. Һәм ул хәзерге көндә татар совет әдәбиятының иң күренекле, эшче һәм крестьяннарнең иң яраткан классик язучысы булып җитеште.

Шәриф ага Камал элекке тормышның бөтен газабын, аның тигезсезлеген үз күзе белән күргән, алай гына да түгел, шул авыр эксплуатацияне үз җилкәсендә татыган язучы. Ул 1884 нче елда, элекке Пенза губернасы, Инсар өязе, Пешлә авылында мулла семьясендә туа. Башта авыл мәдрәсәсендә укый. Ләкин иске мәдрәсәдәге укыту, иске тәрбия аны һичбер канәгатьләндерми. Шәрифнең дөньяга карашы бөтенләй башкача була. 16—17 яшендә чагында ук инде ул үз кул көче белән көн итәргә керешә. Семьясен ташлап чыгып, дөнья гизә башлый. Башта тимер юлда гади эшче булып эшли. Соңыннан Аннинков фамилияле татар баена ялланып, Рига шәһәренә һәм Истамбулга бара. Соңыннан укытучы була. Донбасс шахталарында, Каспи балык промыслоларында эшли. Счетовод та, корректор да, редакция работнигы булып та хезмәт итә.

Октябрьнең беренче көннәреннән үк Шәриф Камал чын күңле белән революциягә кушыла. 1919 нчы елда Төркстан фронты газетасы „Кызыл Йолдыз"да эшли. Һәм шул ук елда коммунистлар партиясе сафына керә. Шул еллардан бирле инде Шәриф ага актив рәвештә революциягә һәм, гомумән, совет художество әдәбиятына хезмәт итеп килә, җәмагат эшләрендә актив катнаша. Ул—Казан Шәһәр Советының депутаты, „Совет Әдәбияты" журналы редколлегиясе члены.

Шәриф ага Камал революциягә кадәр күбрәк кыска хикәяләр-новеллалар яза. Ул бу елларда татар әдәбиятына утыздан артык новелла бирә. Шәриф ага Камал татар әдәбиятында новелла

жанрын үстерүче һәм шул ук вакытта, иң беренче мәртәбә буларак, татар эшчеләре тормышыннан алып хикәяләр яза башлаучы да.

Язучы әсәрләренең күпчелегендә капитализм тырнагында рәхимсез рәвештә изелүче шахтерларны һәм промысло эшчеләрен чагылдыра. Авыр газапта, хокуксыз яшәүче татар хатын-кызларының һәм шул заманның демократик интеллигенциясенең тормышын күрсәтә. Ул үзенең иң беренче мәртәбә басылган (1909 нчы елда) „Уяну" исемле хикәясендә үк тегермән эшчесе Мусаның авыр язмышын, кешелектән чыгуын, семьясенең таркалуын гәүдәләндерә.

Язучы бу процессны коры, схематик рәвештә бирми, ә Мусаның тирән психологик кичерешләре аркылы бирә.

1910 нчы елда басылган „Козгыннар оясында“ исемле хикәясендә инде без Донбасс шахтерларының революциягә кадәр булган тормышын, авыр эксплуатация нәтиҗәсендә кешелектән чыккан Насрый, Габделхәй, Хәлил, Госман карт кебек шахтерларны күрәбез. Язучы үзенең әсәрләрендә кешеләрне стандарт бер кеше итеп күрсәтми, ә кешеләрне чын тормыштагыча, җанлы кешеләр итеп сурәтли. Мәсәлән, шул ук „Козгыннар оясы“ хикәясендә без байтак кына характерларны күрәбез. Менә күп еллар буена шахтадан кайтмый эшләүче „кансыз йөзле“, „күңелгә кайгы сала торган көйләр таратучы“, бер эчсә атна буена туктый алмый эчә торган Насрый типы. Аның белән бергә, шушы әсәрдә үк, йомшак күңелле, кешелекле, авылга кайтып баю турында һаман да әле хиалланучы Госман карт та, шахта хуҗаларына сатылган аумакай Садрый образлары да үзенчәлекләре белән сурәтләнгәннәр.

Үзенең тормышын, эшен һәм әдәби иҗадын хезмәт ияләре белән нык бәйләгән язучы Шәриф ага Камал татар милләтчеләре белән һичбер вакытта да килешмәде. Татар буржуа вәкилләре, милләтчеләр аның иҗадын читләттеләр, аны эшчеләр һәм гомумән хезмәт ияләре тематикасыннан аерырга тырыштылар. Гади эшчеләр турында язу ул сәнгать эше түгел димәкче булдылар. Ләкин Шәриф ага тормышы белән дә, әдәби эшчәнлеге белән дә хезмәт ияләреннән аерылмады. Буржуаз милләтчеләрнең чын йөзләрен ачып „Депутат“, „Сәмруг кош“ кебек көчле сатирик әсәрләрен язды.

Шәриф ага революциягә кадәр язган әсәрләрендә капитализм тормышының авыр, тынчу һавасында яшәгән, кешечә көн итә алмаган, үзләренең кәшелекләрен югалткан, загифләнгән эшчеләр, хатын-кызлар һәм укымышлыларның тормышын бөтен тулылыгы белән күрсәтте. Аларны ул чын күңелдән кызганды, бәхетле итәргә тырышты. Ләкин язучы бу бәхетсезләрне җылы кояш нурлары астына чыгару юлларын аңлау дәрәҗәсенә үзе дә күтәрелмәгән иде әле.

Бөек Октябрьне зур шатлык белән каршы алган язучы яңа тормыш белән бергә үсте, аның дөньяга карашы да үзгәрде. Ул революцияне һәм социалистик ил алдында торган бурычларны дөрес чагылдырган,югары художестволы әсәрләр бирде. „Таң атканда“, „Матур туганда“ кебек зур полотнолы романнар тудырды. „Ут“, „Козгыннар оясында“, „Таулар“, „Томан арты“ кебек драма әсәрләрен язды.

Шәриф ага бүгенге көндә „Матур туганда“ романының икенче кисәген язу өстендә эшли. Аның бу романы сыйнфи көрәшнең дәвам итүе, социализмның җиңүе һәм кешеләр аңындагы капиталистик калдыкларны бетерү кебек иң мөһим бурычларга багышланган.

Без татар әдәбиятында утыз ел буе армый-талмый хезмәт иткән, аңа онтылмас әсәрләр биргән һәм совет балаларының сөйгән язучысы Шәриф ага Камалның тагын да югары художестволы әсәрләр бирүенә чын күңелдән ышанабыз.

А. Әхмәт.

АВЫЛ МӨГАЛЛИМЕ

Ш. КАМАЛ

Бу авылга ул сентябрь 18 ндә кич белән килеп төшкән иде.

Төнлә белән яңгыр явып, иртән салкын вә пычрак булды.

Чәйдән соң мулла, мәзин, тагын чал сакаллы калын гына бер кеше аны мәктәпкә алып бардылар. Мәктәп су янында, озынчарак, зур түгел генә бер бина булып, башы кызылга буялган, тәрәзәләре гадәти авыл өйләренекеннән зуррак булса да, үзе черек вә нечкә агачлардан эшләнгәнгә һәм дә бераз кыйшаеп торганга күрә, тышкы яктан әллә ничди иске су тегермәне, яисә борынгы алпавыт утарларындагы ташланган флигель төсле килешсез вә кызганыч рәвештә күренә иде.

Эченә кергәч мулла, таягы белән стеналарга төртеп-төртеп:

— Әйе,—диде,—менә шул җирләре җәй көне тәмам кибеп ачылган иде. Узган атна гына әле бик һәйбәт кыс-

тырып төзәттердек, әйе. Җылы булыр дип уйлыймыз инде, әйе. Ул, ягни мәсәлән, кыш көне мәктәп салкын булса, әлбәттә, ягни уңайсыз була, әйе. Менә бу бүлмә инде үзегезгә булыр, ягни мәсәлән, үзегез инде шул бүлмәдә торырсыз. Бераз кечкенә кечкенәлеген... Әлбәттә, инде, ягни җәмагатсез кешегә артык тыгыз булмас дип уйлыймыз, әйе...

Мәзин мулланың сүзен куәтләп:

— Әлбәттә, ягни бер кешегә ул хәтле зур бүлмә кирәкми,—дип куйды.

Мөгаллим һәм аларга игтираз[1] кылмады, иске генә чемоданы белән мендәр, юрганын кертеп урнаштырды.

Мулла бу арада сүзне башкага борып:

— Үткән елгы хәлфәмез дә яхшы иде. Ләкин бик ходаи кеше иде, мескен. Шул хәтле, ягни мәсәлән, юаш иде, бичара, кыш буе ник кенә бер баланы чиртсен! Түгел ул кыйнарга да сугарга. Балалар, ягни мәсәлән, тәмам азып беттеләр, әйе...

Бу арада әлеге чал сакаллы кеше, гырылдаган калын тавыш белән:

— Ул мәчеттә коръән да укымыйдыр иде!—дип кыска гына әйтеп куйды.

Мәзин аны төзәтеп:

— Әйе, ягни сирәк укый торган иде,—диде.

Мулла сүзендә дәвам итеп:

— Шулай да мәсәлән, мин аны бик яраткан идем. Ләкин мәхәллә бер дә яратмады, әйе,—диде.

Алар шулай бер унбиш-егерме минутлар сөйләнгәләп, чыгып киттеләр.

Бүген мөгаллим көн буе бер кая да чыкмады. Әйберләрен рәтләп, берничә җиргә хатлар язып маташты...

Икендедән соң бераз йөрергә чыкты. Су буенда казлар, үрдәкләр кайтырга әзерләнгән рәвештә төзәтенеп-төзәтенеп кенә коеналар, кешеләр дә кичке көйгә басып урам буйлап ашыкмыйча гына кайсы ары, кайсы бире узалар, очраган берсе яңа мөгаллимне ачык кына сәламлиләр иде.

Ул башка барыр җир булмаганга күрә, зиярәтләргә барып йөрде, үзенең шәкерт чакларын бераз исәпләп утырды. Авыл өйләре моннан тагын тәбәнәк вә кечкенә күренә иделәр. Мәктәп бераз кыйшайган көе моңаеп: „Я инде кайт, миңа ялгыз бик күңелсез бит“, дип аны чакыра иде. Аның күңле бик рәхәтләнеп китте: мәктәп, мәктәп белән бергә бөтен авыл аңар караган, аны көтә, кирәксенәләр; бик кирәк, бик мөкаддәс[2] нәрсә—яктылык, нур сорыйлар. Шулай итеп бик шатланган көе ул моннан мәктәпкә кайткан иде. Бөтен кичне ул шул шатлык тәэсире белән үткәрде.

Ул көннән бу көнгәчә бер ай тулды, икенчегә китте. Эшләр шәп кенә рәте белән бара, мөгаллим балаларны бер дә аздырмый, мәхәллә һәм аны бик ярата, һәр җирдә мактап күтәреп сөйләгәнлекләре ишетелә. Еш-еш кына үзен ахшамнан һәм дә ястүдән чыгышлый чәйгә алып керәләр, „китап“ сөйләтәләр. Шулай итеп, карттан, яштән танышлары, мохлисләре[3] була башлады. Шул кыска гына вакыт эчендә ул, бу авылга тәмам ияләшә, бу авыл үзенең туган иле кебек, кешеләре үзенең агайэнесе, карләшләре кебек, ягымлы, сөйкемле күренә башлыйлар. Шул кыйшайган мәктәп аңар бик газамәтле[4] бер бина, бер сарай, бер мәркәз төсле тоела, авылның бөтен рухын ул монда тупланган шикелле күрә.

Ул кайчагында, ястүдан соң бүлмәсеннән чыгып, мәктәпнең залы буйлап йөренә. Бу вакытта аның фикере вә уйлары әллә кайларда оча, аның күз алдында әллә ни хәтле авыллар, әллә ни хәтле шундый кыйшайган мәктәпләр вә ул мәктәпләр эчендә дә, моның үзе кебек, җөббәләрен[5] иңсәләренә салган көе парталар арасында йөренеп торган мөгаллимнәр килә. Алар һәммәсе дә тирән фикергә чумган, халыкны ничек ачарга, халыкны аяк өскә бастырырга, халыкны нурландырырга уйлыйлар, алдагы көнне төшенәләр. Гали вә мөкаддәс максатка юнәлгәннәр. Бер вакыт болар һәммәсе дә сискәнеп куркып китәләр! Ерак та түгел бер читтә, диү төсле бер җәнвар тора. „Әй! Сез! Шәһаләтнамаларыгыз кайда? Ниләр укытасыз?“—дип бармак селкә, боларны янап тора. Маңгаенда чынаяк төбе хәтле кокарда!..

Мөгаллим бу вакытта үзенең кечкенә бүлмәсенә кереп китә...

1. Игтираз—каршылык күрсәтмәде.

2. Мөкаддәс—изге, кадерле.
3. Мохлис—күнелгә ошаган кеше.
4. Газамәтле—олылыклы.
5 Җөббә—кием.

...Соң вакытларда мәзин, бу елгы хәлфәне үткән елгы хәлфәгә караганда күп надан дип һәр җирдә сөйләп йөри башлый...

Беркөн мөгаллим әфәнде гадәтенчә, ясту намазыннан кайткач, мәктәп эченә йөренергә дип чыккан гына иде, берәү каты-каты басып, шапылдап килеп керде. Мулла иде. Аның башында семәк очлы чалма бүреге, кулында калын гына имән таягы, чырае алмашынган иде. Ул кергәч тә, сәлам бирмәенчә үк, калтыранган тавыш белән:

— Син мулла кеметтин, кайсы авылныкы буласын?!—диде...

Мөгаллим аптырап:

— Ник, хәзрәт, Мин...—дип әлләни әйтмәкче иде, мулла аның сүзен кисте:

— Юк, син кайсы авылныкы буласың да, хәзер нинди авылда торасың ягни! Беләмсең шуны? Мин әлегә хәтле чыдадым-чыдадым да хәзер инде син мине чыдамнан чыгардың; ах гакылсыз, исәпсез!..

Кем кушкан соң сиңа мәчеттә вәгаз сөйләргә? Кемнең рөхсәте белән сөйлисең? Ягни мәсәлән, мин сиңа бер мәртәбә сөйләргә рөхсәт бирдем бит, бер мәртәбә, ягни мәсәлән, беләмсең шуны? Ә син ничә тапкыр сөйләдең инде! Сорау кайда да, эзләү кая?! Хәтемне тагын синнән башка укучы юкмыни, ягни мәсәлән, мәзин укымыйммы? Һәр көн сайраган буласың, әйе! менә моннан ары, мәсәлән, вәгаз сөйләгән булып лыгырдап халыкка, акыл сатасың икән, ул чагында эзең дә булмасын монда, ягни мәсәлән! Күрше авылдан мулла Фәтхулланың углын чакыртабыз. Аңладың, ни әйткәнне? Менә шул!

Ул сөйләгән вакытта, мөгаллимгә якын ук торып, таягының башын мөгаллимнең борны төбендә үк әйләндерә иде...

Ул, эчендәге бар ачуын бушаткач, ишекне бик каты ябып чыгып китте. Мөгаллим, ялгызы гына калып, тәрәзә янына барып терәлде. Һава болытлырак булса да, азрак ай яктысы да чагылып-чагылып тора, мулла таяк очы белән бозлавык җиргә нык кына бәрепбәреп урам аркылы күчеп бара иде. Әнә, мәзиннең тәрәзәләре яп-якты, өстәлдә самовары кайнап, булар чыгып тора бугай... Мулла анда керде.

Мөгаллим, байтак вакыт тәрәзә янында терәлеп торгач, идән буйлап йөри башлады, вә аның күз алдына янә теге авыллар, мәктәпләр, мәктәп эчендәге мөгаллимнәр килә иде. Гүя аларны да мулла абзыйлар шулай кереп сүгеп чыгалар, гүя алар да шулай тәрәзә янына килеп терәләләр...

Ул, бик озак идән буенча йөрегәч, бүлмәсенә кереп чишенми-нитми кроватына сузылып ятты. Үзе теләп бер нәрсә дә уйлый алмый иде. Әллә нинди бер-беренә мөнасәбәте булмаган кыска, магнәсез әйберләр аның башына кереп-чыгып йөри иделәр. Түшәмдә әллә нинди саргылт күлчәләр күренә башлады. Бөтен бүлмәне тутырдылар, бүлмә ифрат тыгыз булды! Бер вакыт шул сары тап вә күлчәләр арасыннан теге кокардалы нәрсә, тешләрен кыҗырдатып: „Мин бирермен сиңа укыту!"—дип йодырыгын моның күз алдында бутый башлады. Аннан мулла, чалма бүреген очландырып чикәсенә кыңгыр салган, сакал очын аузына капкан көе: „Мин сиңа күрсәтермен күрмәгәннәреңне!" — дип имән таягының башын мөгаллимнең борны төбендә әйләндерә иде... Теге чал сакаллы кеше дә, чыраен сытып, шунда артта гына әллә ни әйтмәкче булып тора иде...

1910.





Сөекле ата

Үндүрт яшлек Ярослав, Тарнополь шәһәреннән ерак түгел генә урнашкан, украин авылында яши. Аның атасын коммунистларга теләктәшлек иткәне өчен моннан өч ел элек кулга алдылар һәм Тарнополь төрмәсенә илтеп яптылар.

Менә өч ел инде алар, үзләренең җимерек йортларында, әнисе Наталия белән икәү генә яшиләр...

Менә өч ел инде Ярослав атасыз...

1939 ел.

Уналтынчы сентябрьнең караңгы төне...

Ярослав та, Наталия дә эштән бик соң һәм бик нык арып кайттылар. Бер сынык кара икмәкне икесенә бүлеп ашадылар да, йокларга яттылар. Ләкин Ярослав йоклый алмады. Аның башында шомлы уйлар йөрде. Ул уйлар аның күңлен тынычсызландырдылар, аңа йокыга китәргә ирек бирмәделәр... Ул бабасы Мацкодан бүген генә ишеткән хәбәрләр турында уйланып ятты...

Күрше авылда жандармнар коммунист Еремконың хатынын һуштан яздырганчы кыйнап, газаплап киткәннәр...

Әгәр дә аның әнисенең сугышка каршы крестьян хатыннары арасында агитация алып баруын белсәләр!.. Аны асып үтерәчәкләр бит!.. Ярослав анасыз калачак!

Ярославның башында шундый уйлар йөрделәр. Ул аларны таратырга теләде, уйларын икенче нәрсәгә борып карады. Ләкин һаман шул ук уйлар аның башына килеп төштеләр һәм аңа тынычланып, йокыга китәргә ирек бирмәделәр. Ул йокларга тырышып күзләрен йомып карады, ләкин йокыга китә алмады. Озак шулай җафаланып ятканнан соң, ул, ниһаят, йокыга китте. Ләкин күп йоклый алмады, каты итеп ишек дөбердәткән тавышка уянды. Әнисе, эштә бик нык арыгангамы, бик изелеп йоклый иде әле. Ярослав кырык ямаулы, иске юрганы астыннан башын калкытып:

— Кем бар анда?—дип сорады. Тыштан калын, тупас тавыш иштелде:

— Ачыгыз! Әллә үлдегезме?!

Ярославның бөтен тәне буенча эссе йөгерде. „Мондый тупас тавыш белән жандармнар гына сөйләшә“дип, уйлады ул. Куркудан аның бөтен гәүдәсе калтырана башлады... Тыштан, беренчесенә караганда да тупасрак, икенче тавыш ишетелде:

— Ачыгыз! Юк исә ишегегезне ватабыз!

Бу тавышка Наталия дә уянды.

— Нәрсә бар?! — дип сорады ул борчылып. Аңа җавап бирүче булмады...

Ярослав, нәрсә эшләвенә үзе дә хисап бирә алмыйча, урыннан сикереп торды да, ишек ачты. Жандармнар дөбердәп өйгә килеп керделәр. Арада иң тупасы — жандарм начальнигы ишектән керү белән Наталиягә акырды:

— Йоклыймсың, быдло[1]?! Без хәзер синең йокыңны ачарбыз!

— Сезгә нәрсә кирәк? — диде Наталия.

— Молчать! Быдло! Менә без сиңа хәзер ничек коткы таратырга икәнен күрсәтербез! — дип акырды жандарм начальнигы һәм: „Бәйләгез үзен!“, — дип жандармнарга приказ бирде. Жандармнар, үлек гәүдәгә ябырылган шакаллар кебек, дүртәүләшеп Наталиягә ябырылдылар һәм бау белән аның аяк-кулларын бәйләделәр. Ярослав, куркып сте-

---

1 *Быдло — элекке паннар Польшасенда украиннарны мыскыллап әйтелгән сүз.*

нага сөялгән хәлдә, жандармнарның һәрбер хәрәкәтләрен күзәтеп торды...

— Камчылагыз! — дип приказ бирде жандарм начальнигы. Жандармнар Наталияне камчылар белән кыйный башладылар. Наталия, тәненең әрнүенә чыдый алмыйча, кычкырып җибәрде. Әнисенең әрнүле тавышы Ярославның йөрәгенә уктай кадалды. Ул куркуны онытты. Аңарда ачу кабынды. Ул:

— Тимәгез әниемә! — дип, жандармнарның камчыларына барып ябышты. Бу хәлгә жандарм начальнигының ачуы кабарды һәм ул кызарынды, бүртенде дә:

— А! Көчек! Әле синең дә кыйналасың киләмени? Ярыгыз үзен! — дип, Ярославның битенә камчы белән сукты. Жандармнар Ярославны камчыларга керештеләр. Наталия:

— Тимәгез аңа! Бала бит ул, бала! — дип ялварса да, аны кыйный-кыйный, урам уртасына чыгарып ташладылар...

Ярославның бабасы Мацко, аларга каршы йортта тора иде. Ул ниндидер көчле яктылыкка күзе чагылып, төн уртасында йокыдан уянды. Урыннан торып, тәрәзәгә карады. Урамның теге ягында Наталияләрнең йорты яна иде. Мацко борчылып, тиз генә киенде дә, ашыгып урамга чыкты. Урамга чыгу белән, туфракта аунап яткан Ярослав аның күзенә чалынды. Ярославның хәрәкәтсез гәүдәсен пожар уты яктырта иде...

Урамда бер кем дә юк, бары тик атка атланган жандармнарның авылдан чыгып китүләре генә, ут яктысында күренеп калды...

Мацко тиз генә Ярослав янына килде дә, борчылып:

— Ярослав, сиңа ни булды?! Ярослав, ни булды?! — дип берничә тапкыр кабатлады. Ләкин Ярослав аңар җавап бирмәде. Ул һушсыз иде... Мацко аның гәүдәсе өстенә күзен текәде дә, ачы әрнүле уйларга чумды...

Ә Ярославларның йорты өстендә ялкын күтәрелгәннән-күтәрелә барды. Пожар яктысына уянып урамга чыккан халык Ярославларның йорты янына җыела башлады...

— Пожар! Пожар! — дигән тавышлар авыл урамын яңгыраттылар...

Җыелган халык ашыгып пожар сүндерергә кереште. Ә Мацко Ярославның хәрәкәтсез гәүдәсе өстенә карап, катып калган хәлдә, басып торуында дәвам итте. Аның чырае әрнү катыш нәфрәт белән тулган. Аның куе кашлары тоныкк күзләрен каплаганнар.

Кинәт, яна торган йорт эченнән ачы тавыш ишетелде:

— Үләм, туганнар, коткарыгыз!..

Бу тавыш ишетелгәч, Мацконы яшен суккан кебек булды. Ул сискәнеп китте... Мацко ул тавышны бик тиз таныды. Ул тавыш аның кызы, ә Ярославның анасы—Наталия тавышы иде. Мацко Наталияне коткарырга ашыкты, пожарга таба омтылды. Ул тизрәк йорт эченә атылырга теләде. Тизрәк һәм ешрак атларга тырышты. Ләкин аяклары тыңламадылар. Чиксез курку һәм каушаудан карт Мацконың аяклары хәлсезләнгәннәр иде. Ярослав яныннан 2—3 адым атлагач та, ул сөртенеп егылды...

Шул вакыт кемдер кычкырып җибәрде:

— Мин аны үзем коткарам! Син борчылма, Мацко!

Бу тавыш Мацконың күршесе Карась тавышы иде. Мацко егылган җиреннән көч-хәл белән торды да, Карасьнең тавышы ишетелгән якка карады. Ләкин анда Карась юк иде инде. Карась күптән ут эченә кереп югалган иде...

Мацко Карасьнең ут эченнән чыкканын түземсезлек белән көтте. Ә халык ашыга-ашыга пожар сүндерде.

Берничә минуттан соң ялкын эченнән Карась атылып килеп чыкты. Ләкин ул бер үзе генә иде... Аның күлмәге яна иде, аның өстенә бер юлы берничә чиләк су сиптеләр. Ул еш-еш сулап берникадәр хәл җыйды да, күңелсезләнеп:

— Йорт эченнән мин Наталияне таба алмадым,—диде.

Мацконың йөрәгенә хәнҗәр кадалгандай булды. Димәк, үзенең кызын, яраткан кызын, ул хәзер мәңге күрмәячәк. Хәтта аның үлек гәүдәсен дә күрә алмаячак...

Мацконың көчсез аяклары, аның гәүдәсен күтәреп тора алмадылар. Ул Ярославның хәрәкәтсез гәүдәсе янына, туфракка егылды. Ярославның күкрәгенә башын салды да, битен кулы белән каплап, үксеп-үксеп җылады.

Карась ашыгып алар янына килде.

— Мацко... Мацко...—дип эндәште ул. Лэкин Мацко аны ишетмәде. Үксиүкси җылавын дәвам иттерде. Бары тик Ярославның ыңгырашып, кыймылдап куюы гына аны аңына китерде.

— Карась,—диде ул каушаган, өметсез тавыш белән,—Ярослав туфракта аунап ятмасын, аны минем өйгә алып керик...

Карась Ярославны җай белән генә күтәрде дә, Мацконың өенә алып кереп китте.

Пожарны сүндергәннәр иде инде.

Мацко урыныннан торды да, кызы Наталиянең күмергә әйләнгән гәүдәсен булса да күрергә өметләнеп, пожар булган урынга таба атлады... Ул күмерләр, көлләр, кирпечләр арасыннан озак эзләнде... Лэкин Наталиянең гәүдәсен таба алмады. Ниһаять, өметен өзеп, тирән итеп авыр сулады да өенә кереп китте.

Мацко өенә кергәндә Ярослав һушына килгән иде инде. Карась аның яраларын бәйләгән һәм маңлаендагы кипкән чүпрәкне юеш чүпрәк белән алмаштыра иде. Лэкин Ярослав еш-еш кына ыңгыраша иде әле...

Мацко өметсез адымнар белән өстәл янына килеп, урындыкка утырды да, тирән уйга чумды. Аның күзләре бер ноктага текәлделәр. Аның күзләренә яшь килде. Ул бер сүз дә дәшмичә, озак уйланып утырды...

Кинәт аның кашлары җыерылдылар, аның маңлаендагы тирән җыерчыклар тагы да тирәнәйделәр, ул әрнүле тавыш белән:

— Лагнәт яусын паннарга!,—дип кычкырып җибәрде. Һәм өметсез тавыш белән әрнеп өстәп тә куйды:

— Минем кебек ярдәмсез калганнар турында, Ярослав кебек ятимнәр турында бер генә кайгыртучы да юк бит, Карась!—дип, Караська таба борылды.

— Ялгышасың, Мацко,—диде Карась.— Сезнең турыда кайгыртучы бар. Сезнең турыда, минә безнең турыда, бөтен изелгән халыклар турында көн саен, сәгат саен, минут саен кайгыртып торучы бар...

— Кем соң ул?!—диде Мацко аның сүзен бүлеп.

— Ул,—диде Карась,—большевиклар партиясе! Ул—Сталин!

Тәне әрнүдән Ярославның йөзе җыерылган, чырае сытылган, кашлары җыерылган иде. Карасьнең соңгы сүзләрен ишеткәч, аның йөзе ачылып китте, кара күзләре яктырып китте. Бу минутта ул, тәненең әрнүен дә онытып җибәрде. Иреннәрен көчкә-көчкә генә кыймылдатып, Карасьнең соңгы сүзләрен кабатлады:

— Ул—Сталин!..

Шул сүзләр белән Ярослав йокыга китте.

Икенче көн төш вактында маңлаена ниндидер юеш нәрсә тигәч, Ярослав уянып китте. Аның маңлаена тигән юеш нәрсә—Мацконың иреннәре иде. Ярослав күзен ачканда Мацконың салкын иреннәре аны үбәләр иде әле. Ярослав иреннәрен көчсез генә кыймылдатып, балаларча бер катлылык белән Мацкога сорау бирде:

— Бабай, син мине үптең? Ни өчен?

Мацконың йөзендә кичәге өметсезлекнең әсәре дә калмаган иде. Аның гадәттәге тоныкк, сүнгән күзләрендә бүген яктылык, киләчәгенә зур өмет белән яшәүче кешеләрдәгедәй яктылык балкый иде. Ул Ярославның соравына, күтәренке рух белән җавап бирде:

— Эх Ярослав! Мин бүген сине үпмичә булдыра аламмы соң? Бүген безнең изелгән халыкларның бәйрәм көне! Бүген безгә ярдәмгә Кызыл Армия килә.

Ярослав Мацконың соңгы сүзләрен ничек кабул итәргә дә белмәде. „Өнемме бу, төшемме?“—дип уйлады ул. Аның шатлыктан тыны кысылды. Ул иреннәрен көчкә-көчкә генә кыймылдатып:

— Чынмы?..—дип сорады.

— Чын! Чын!—диде Мацко,—бөтен авыл халкы шул хәбәр белән рухланган. Кайсы гына өйгә барып кермә, һаман бер үк сүзләрне, бер үк шатлыклы сүзләрне ишетәсең: „Кызыл Армия килә! Безгә ярдәмгә Кызыл Армия килә!..“

Шул вакыт урамнан кинәт ат аягы тавышлары ишетелде. Мацко яшен тизлеге белән урыныннан торып, тәрәзәгә барып карады. Тәрәзәдән урамдагы котчкыч күрнешне күреп артка чигенде. Калтыранган аяклары аны егылудан көч-хәл белән генә саклап калдылар.

Авылга полякларның атлы отряды килеп керде... Алар атларын бөтен көчкә чаптырдылар һәм урамда очраган һәрбер кешенең башларын кисеп үттеләр. Ике минут та үтмәде, алар авылдан чыгып югалдылар. Ләкин шул ике минут эчендә генә дә, алар акылга сыймаслык ерткычлык эшләргә өлгерделәр: авыл урамында унлап кешенең үлек гәүдәсе, туфракта аунап ята иде инде.

Мацко яңадан тәрәзә янына килде дә, эченә җыелган ачуны тотып тора алмыйча:

— Ерткычлар! Бу сезнең соңгы ерткычлыгыгыз булыр! Бу сезнең үлем алдындагы тыпырчынуыгыз булыр!—дип кычкырып җибәрде. Аның тавышына, урамнан ишетелгән көчле „ура!“ тавышлары кушылдылар...

Авылга, поляк бандаларын куа баручы, атлы взвод—данлыклы буденныйчылар килеп керделәр.

Менә... Менә алар, азатлык армиясенең вәкилләре! Кара, алар нинди җитезләр! Алар артыннан күзәтеп калырга күз дә өлгерә алмый...

Бу минутта Ярослав тәненең әрнүен дә, үзенең авыру икәнен дә онытып, тәрәзә янына килде. Бабасы белән янәшә басып, ул кызыл кавалеристларның ат өстендә җил кебек очуларын, тәрәзә аша күзәтә иде инде...

Аның шатлыктан йөрәге ешрак тибә башлады. Ул ешрак сулый башлады. Аның кызыл кавалеристлар белән бергә ат өстендә очасы килде. Әле генә авыл кешеләрен суеп киткән поляк бандасына каршы батырларча сугышасы килде аның!

Авылга кич-кырын Кызыл Армиянең бер рота пехотасы килеп керде. Авыл халкы кызыл армеецләрне көчле „ура!“ тавышлары белән котлый, рәхмәтләр әйтә...

Әнә бер төркем кызыл армеецләрне халык чолгап алган. Халык аларга үз йөрәкләреннән чыккан иң җылы сүзләр белән чиксез рәхмәтләр белдерә.

Әнә бер төркем халык политрукның тирә-ягын әйләндереп алган. Алар арасында Мацко да, Ярослав та бар...

Ярослав шатлыктан ни әйтергә дә белмичә, политруктан күзен алмыйча, аның янында озак басып торганнан соң, тәнендәге эсселектән кипкән иреннәрен кыймылдатып:

— Сездә Сталинның рәсме юкмы?—дип сорады. Политрук сумкасыннан „Правда“ газетасы алды да Ярославка бирде. „Правда“ның беренче битендә Сталинның портреты урнаштырылган иде.

Ярослав бик озак, күзен алмыйча, Сталинның портретына карап торды. Шатлыктан аның күзләренә яшьләр килделәр... Карасьнең кичәге сүзләре аның исенә төште дә, аның кипкән иреннәре яңадан кыймылдадылар:

— Әйе! Безнең турыда кайгыртучы бар! Менә ул! Менә!—диде дә, Ярослав кайнар рәвештә Сталинның портретын үпте. Ул яңадан портретка йотлыгып карады, һәм бу баланың иреннәреннән, һәр кемнең уен, һәр кемнең тойгысын чагылдырган сүзләр көчле булып яңгырап чыкты:

— Менә ул минем иң сөекле, иң кадерле атам!

Фаик Камал.

ДЖОРДАНО БРУНО

Бөек галим Николай Коперник 1543 нче елда „Күк сфераларының әйләнүе“ исемле китабын бастырып чыгарды. Яңа астрономия фәненең башланып китүен менә шул вакыттан исәплиләр. Китабы чыккан елда ук Коперник үлә. Италия галимнәреннән Джордано Бруно һәм Галилео Галилей фән өлкәсендә революция ясаган бу галимнең китабындагы фикерләрне киң рәвештә халыкка аңлаттылар, Коперникнең фикерләрен тагын да югарырак күтәрделәр. Чиркәү башлыклары фәндәге бу яңалыкларга бик нык каршы килделәр, чөнки Коперник, Бруно, Галилей аңлатулары динчеләр язган китаплардагы аңлатуларга капма-каршы иделәр. Католик дин башлыклары фәндәге һәрбер яңалыкны юк итәргә тырыштылар. Галимнәрне эзәрлекләделәр, үтерделәр.

1616 нчы елда Коперникның китабын утка яктылар. Ә 1633 нче елда Галилейне үз фикерләреннән кайтырга көчләп мәҗбүр иттеләр. Вахшиләрчә газаплауларга да карамастан, галимнәр эшләрен дәвам иттерделәр. Кара фикерне, динне фән барыбер җиңеп чыкты. Кеплер, Ньютон, Лаплас, Дарвин кебек бик күп галимнәрнең тырышлыгы белән астрономия фәне нык үсте.

Джордано Бруно 1548 нче елда Көньяк Италиядәге Нолу шәһәрендә туган. Ул яштән үк белемгә омтыла. Философия фәнен тынычрак урында өйрәнү теләге белән, Джордано 1562 нче елда монастырьга керә һәм анда унике ел буена яши. Биредә ул борынгы фәннәрне һәм яңа галимнәрнең фикерләрен өйрәнеп, үзе дә китаплар яза башлый. Коперникның „Күк сфераларының әйләнүе“ исемле китабын укыгач, Джордано шул өлкәдә эшләргә керешә. Ул Коперникның аңлатуын киңәйтә һәм тирәнәйтә, җирнең һәм планеталар системасының хәрәкәт итүләрен аңлаткан үзенең теориясен эшләп чыгара.

Джордано Бруно монастырьдагы кысуларга чыдый алмый. Шуңа күрә ул монахлык киемен ташлап, монастырьдан кача. Ул шуннан соң төрле шәһәрләргә, төрле илләргә барып йөри. Рим, Генуя, Турин, Венеция, Радуя, Шамбери, Женева, Тулуза, Париж, Лондон, Оксфорд һәм Германиянең күп шәһәрләрендә була. Университеты булган шәһәрләрдә ул ике-өч елга тукталып, анда лекцияләр сөйли. Һәрбер булган җирендә ул яңа фикерләр әйтә, диспутлар оештыра. Үзенә ул „Йоклаганнарны уятучы, мактанчык һәм тупасларны җәзалаучы“ дигән исем бирә.

Коперникка кадәр — кояш җир тирәсендә әйләнә, дип йөргәннәр. Коперник—киресенчә, кояш тирәсендә җир һәм башка планеталар әйләнә дип өйрәтә. Джордано Бруно күк йөзен Коперниктан да киңрәк аңлый.

Бруно үзенең фикерләрен популярләштерүне лекцияләр белән генә чикләмичә, итальян һәм латынь телләрендә китаплар да бастырып чыгара. Ул латынь, грек, француз, итальян, испан телләрен бик яхшы белә. „Чиксезлек, күк йөзе һәм күктәге әйберләр турында“ исемле китабында Бруно кайбер нәрсәләрне күп еллар элек алдан күрә. Мәсәлән, ул билгеле булган планеталардан тыш та планеталар барлыгына ышана.

Джордано Брунонын фикерләре чиркәүнең аңлатуларына каршы килгәнгә, дин башлыклары аның ирекле фикрен юк итәргә маташалар. Ләкин Джордано чит илдә качып йөри. Шулай, унбиш еллап чит илдә йөргәч, Джордано Бруно үзенең туган иле Италияне бик сагына башлый. Һәм саксызлык күрсәтеп, 1592 нче елда, Италиядәге Венеция шәһәренә кайта. Кайту белән үк аны кулга алалар. Шуннан соң җиде ел буена ул Венеция, Рим төрмәләрендә ята. Аны төрлечә җәзалыйлар. Фикерләрең кире кайтарып алырга, фикерләрен юкка чыгарырга кушалар. Ләкин Джордано үз сүзендә нык тора. 1599 нчы елның декабрендә аңа соңгы мәртәбә фикерләрен кире кайтарып алырга кушалар. Уйларга 40 көн вакыт бирәләр. Ләкин Джордано үзенең фикерлә-

(Дәвамы тышлыкның өченче битендә).

Җаваплы редактор **Г. ХӘБИБУЛЛИН.**

Ответств. редактор **Г. ХАБИБУЛЛИН.**

Заказ № 784. 2 табак. Табакта 70.700 знак. Главлит вәкиле № 891. Производствога бирелде 4/II—40 ел. Басарга кул куелды 28/II—40 ел. Тираж 8089. Кәгаз форматы 70×108.

Александров исемендәге типография. Казан, Бауман урамы, 19. 1940.

реннән кире кайтмый. Ул 40 көн үткәч тә фикерләреннән кире кайтырга теләмәгәнлеген белдерә.

Рим папасы 1600 нче елның 20 нче январендә Джордано Бруноға „кан коймыйча юаш һәм рәхимле җәза“ бирергә кушып карар чыгара. Чиркәү теленнән гади телгә күчереп әйткәндә, бу җәза—хөкем ителүче кешене тереләй яндырып үтерергә дигән сүз.

1600 нче елның 16 нчы февралендә, Римдагы Чәчәкләр мәйданына меңнәрчә кешеләр җыела. Бер туктамый колоколлар кагып, зур бәйрәм булачагы турында белдерелә. Католик поплары латынь телендә догалар укып, мәйданга иң алдан киләләр. Алар артыннан өстенә сары төстәге, килешсез, киң һәм озын кием кидертелгән Джордано Бруно алып барыла. Аның киеме өстенә шайтан рәсемнәре ясалган, башына кәгаз калфак кидерелгән. Калфакның очына ялкыннар белән чорналып алынган кеше рәсеме эшләнгән була. Джордано богауланган хәлдә атлап бара. Аның артыннан тагы руханилар баралар. Иң ахырдан гына хөкүмәт кешеләре белән дворяннар сафы атлый.

Джордано Бруноны бик ныклап баганага бәйләп куялар. Аяк астына өелгән утыннарга ут төртәләр. Ялкын зурая барып, озакламыйча бөек галим Джордано Брунoның тәнен дә үз кочагына ала, ул яна башлый. Шундый авыр җәзага ул нык чыдый, хәтта ыңгырашмый да.

Безнең илебездә фән бик алга китте. Хәзер бездә җирнең кояш тирәсендә әйләнүен генә түгел, аннан да катлаулырак мәсьәләләрне аңлату өчен тикшерүләр алып барыла. Мәсәлән, хәзер антиподлык гипотезасы нигезендә йолдызлар, кояш, планеталарның килеп чыгуы тикшерелә. Бездә яңа Коперниклар туалар!

Хәмит Кави.

ГЕОГРАФИК КРОССВОРД

ГОРИЗОНТАЛЬ БУЕНЧА:

1. Чехиядәге шәһәр.
6. СССР ның Азия өлешендәге елга.
7. Франциядәге порт.
9. СССР ның Европа өлешендәге елга.
12. Франциядәге шәһәр.
14. Ленинград өлкәсендәге елга.
15. Англиядәге елга.
16. Италиядәге елга.
17. Сена елгасындагы порт.
20. Рейн елгасының кушылдыгы.
22. Вислага коючы елга.
24. Печора елгасының кушылдыгы.
25. Африканың төньягындагы порт.



ВЕРТЕКАЛЬ БУЕНЧА:

2. Гарәбстандагы шәһәр.
3. Американың иң көньяк мысы.
4. Швейцариянең башкаласы.
5. Төньяк Франциядәге порт.
8. СССР ның төньягындагы елга.
10. Кыргызстандагы шәһәр.
11. Сена елгасының уң кушылдыгы.
13. Франциядәге шәһәр.
14. Аляскадагы шәһәр.
18. Таҗикстандагы елга.
19. Казахстандагы елга.
21. Азиядәге диңгез.
22. Азәрбәйҗандагы зур шәһәр.
23. Кавказдагы шәһәр.

КАМИЛ БИЧУРИН.

Казан, элемтә ФЗУ укучысы.

ТЫШЛЫКТА: **Хәрби занятиедә.** Художник А. Палуев рәсме.

ТӨЗӘТҮ

Журналыбызның быелгы январь номерында, 26 нчы биттә, „Россияне уятучы көчле набат“ дигән мәкаләнең исеменнән соң язылган сүзләрне **„(Герценның үлүенә 70 ел тулу уңае белән)“** дип төзәтеп укуыгызны сорыйбыз.

Редакция.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

„ПИОНЕР КАЛЯМЕ“

ЕЖЕМЕСЯЧНЫЙ ЖУРНАЛ ПИОНЕРОВ И ШКОЛЬНИКОВ
ОРГАН ОБКОМА ВЛКСМ И НАРКОМПРОСА ТАССР.